## ДУСЛЫК КҮПЕРЕ
Якутиядә Татарстан көннәре уза
> 2



## УКУЧЫ СҮЗЕ
«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары
> 3

## НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар
> 4

## КИҢКЫРЛЫ ШӘХЕС ИДЕ
Татар җәмәгатьчелеге Фатыйх Сибагатуллин белән хушлаша
> 5


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 89 (28862) | Шимбә | 25 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131


**27 июньдә Россиядә Яшьләр көне билгеләп үтелә. Такташ язганча, гомере кыска яшьлекнең төсе, асылы нинди бүген? Заман яшьләре – кемнәр алар? Аларны нәрсә борчый? Хәзерге чор яшьләренә нәрсә җитми?**

Бәйрәм алдыннан без, әнә шул сорауларга җавап эзләп, яшьләрнең үзләренә мөрәҗәгать иттек. Җырчы Илнар Шәрәфетдинов сүзләренчә, бүген яшьләр өчен ирек һәм гаделлек төшенчәсе аеруча мөһим.

– Һәр кеше – кабатланмас, һәркем дөньяны үзенчә күрә. Миңа калса, бүгенге яшьләр өчен ирек, гаделлек кебек төшенчәләр аеруча мөһим. Иҗат белән көндәлек тормыш арасында бәйлелек көчле. Тормышта да, иҗатта да сәләтле, булган яшьләр бик күп. Аларга бары юл бирергә генә кирәк, – ди ул.

Шагыйрь Фәнил Гыйләҗев, кемнән ни көтәсен чамалау кыен, дигән фикердә:

– Яшьләргә гомуми бәя биреп булмый. Алар бик тә төрле. Кызыксынулары да, дөньяга карашлары да һәркемнең шәхси, үзенчә. Барысын да бер калыпка кертеп карарга ярамый да торгандыр ул. Кемнең нинди булуы кайда нинди тәрбия алуыннан, мохитеннән, яшәү рәвешеннән тора.

Бүгенге яшьләр барчасы диярлек интернетлы смартфоннарга ия, шуңа күрә күпчелеге дөньякүләм мәгълүмат белән эш итә белә, үзе чагыштырып, күп мәсьәләләрне анализларга сәләтле. Билгеле ки, алар, бер яктан, дөньяда һәм илдә барган вакыйгаларга, гаделсезлекләргә карата битараф түгел. Шул ук вакытта нәрсәгә ышанырга белмичә аптыраучылар, кыйблаларын җуйганнар да күп. Икенче яктан, барыбер нидер үзгәртә алачагына ышанычы, таяныр ноктасы булмаганлыктан, гаҗизлектән яки яшьлегенә күрә – битарафлыкта яшәүчеләр дә бар. Яшьләргә генә түгел, гомумән кешеләргә төрле агымнар, фикер-идеологияләр тирәсендә берләшү хас. Шул ук вакытта, минемчә, бүген күп яшьләр үз дөньясында, ә кайчак бөтенләй дә виртуаль дөньяда яши. Шул сәбәпле җәмгыять кемнән ни көтәсен чамалап та бетерә алмый.

Ә акча санарга бик иртә өйрәнгәннәрне – яшь эшмәкәрләрне нәрсә борчый соң? «Бирнә» бренды дизайнеры Камилә Мостафина әйтүенчә, алар очраша торган каршылыклар акчага гына кайтып калмый.

– Яшьләрне киләчәк борчый. Үзләренең киләчәге. Ике-өч елдан соң нәрсә булачагын бүген күз алдына да китереп булмый. Җәмгыять шулай корылды ки, бүген үз-үзеңне табу бик тә кыен. Менә шушы билгесезлек куркыта. Яшь буынга дөрес юнәлеш бирә алырдай остазлар җитеп бетми. Безнең барысын да үзгәртеп ташлыйсы килә, ләкин акча һәм башка төрле каршылыклар килеп баса. Шул ук матди якны гына алыйк. Яшерен-батырын түгел, җәмгыять шуның тирәли әйләнә. Хыялыңны тормышка ашырыр өчен,

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) яшьләрдән: «Сезнең өчен тормышта нәрсә мөһим?» – дип сораган. Иң популяр җавапларны (процентларда) тәкъдим итәбез.

minmol.tatarstan.ru

# ИЯРТЕРСЕҢМЕ, ЯШЬЛЕК?

башлангыч капитал мәсьәләсен хәл итү кыен. Дәүләт ярдәме була торып та, беренче елларда шактый авырга туры килә. Безнең төбәктә кече бизнес өчен мөмкинлекләр бик күп, тик башка уңышлы брендлар янәшәсендә аерылып тору, игътибарны яулау шактый авыр. Миңа калса, яшь эшкуарлар өчен бу юнәлештә берникадәр ташламалар җитми.

16 яшьлек сыр ясау остасы Данияр Гомәров фикеренчә, сайлау мөмкинлеге күбрәк булган саен кыенрак:

– Без күпмедер дәрәҗәдә максималист: барысын да сайлап карыйсы килә, ләкин булдыра алмыйбыз. Шул ук вакытта арасыннан берсен сайлау да кыен. Күп өлкәдә шулай. Аннан соң, яшьләргә акча җитмәү дә – табигый нәрсә. Көн дә диярлек яңа ачыш ясыйлар, техник прогресс заманында яшибез. Барысын да кулланып карыйсы килә, файдалысын да, кызыксындырганын да. Шуңа күрә матди мәсьәлә – беренче урында. Шулай ук яшьләрнең күп кенә борчулары шәхси һәм һөнәри үсеш тирәсендә тупланган. Вакыт җитми. Озаклап уйларга, күп нәрсәне ныклап торып анализларга мөмкинлек юк.

Яшьләргә иярергә һәм артларыннан калмаска кирәк. «Идел» яшьләр журналының баш мөхәррире Айсылу Хафизова әнә шундый фикердә.

– Яшьләр журналында эшләгәч, алар белән еш очрашырга, аралашырга туры килә. Хәзер безгә минем кызымның яшьтәшләре килә башлады. Алар – бөтенләй башка төрле. Башка планетадан, диярсең. Фикерләүләре, мантыйклары безнекенә охшамаган. Амбицияләре башка яисә бөтенләй юк. Кыскасы, аларны безнең буын белән чагыштыру мөмкин түгел. Шуңа да бүгенге яшьләрдән безнеке кебек максатлар көтүнең мәгънәсе юк. Ләкин бу әле, алар бездән начаррак, дигән сүз түгел. Аларга карап, мин үземне 10–20 елдан соң нинди җәмгыятьтә, нинди дөньяда яшәячәгемне чамалыйм. Тормыш яшен тизлеге белән үзгәрә бит. Һәм яшьләр яңа тормышка яраклашыр өчен күнекмәләр булдырырга тырыша. Минем аларга өметем зур. Яшьләргә карап өйрәнергә, артларыннан калмаска кирәк. Безне киләчәк белән тоташтыручыларга иярмәсәң, үткәндә калачаксың. Андый кешенең гомере кыска һәм мәгънәсез булачак, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

**Белгеч фикере**

**Зөһрә КӘРИМОВА, практик психолог, психология фәннәре магистры:**

– Бүгенге яшьләр гаҗәеп төрле. Ләкин проблемалары уртак – үз-үзләренә ышаныч җитми, тормышта үз урыннарын таба алмыйлар. Кеше белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләр дә – «йомшак» урыннары. Яшьләргә ихтыяр көче, сабырлык, мотивация һәм иң мөһиме – максатчанлык җитеп бетми. Күпләр нәрсәдер тели, ләкин нәрсә икәнен тәгаен белмәгәнлектән, каршылыкларга юлыга. Ә кайберәүләргә, әйткәнемчә, мотивация җитми, шуңа да алар эшне ярты юлда калдыра, яңадан башларга куркалар.

## Хаталар өстендә эш

Юстиция министрлыгы 4 ел эчендә республиканың 38 авылы атамасындагы хатаны төзәткән. Авыл исемнәре Дәүләт географик атамалар каталогында күрсәтелгәнгә туры килмәгән. Юк-бар гына тоелган хаталар җирле халыкка күчемсез милек белән төрле алыш-бирешләр ясаганда, яшәү урыны буенча теркәлгәндә җитди кыенлыклар тудырган.

Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, министрлык хезмәткәрләре белән Росреестр вәкилләре, барлык атамаларны уртак язылышка китерү өчен, зур эш башкарган. Асылда сызык куелу-куелмауда, баш хәрефне юл хәрефеннән язуда (яки киресенчә) һ.б. аермалар табылган.

## *Бурычка алучылар кимегән*

Май аенда Татарстанда барлыгы 74534 микрозаем бирелгән. Бу – февральдәгегә караганда 2,6 процентка кимрәк: кышкы айда республикада яшәүчеләр «хезмәт хакына кадәр» 76545 кредит алган.

Илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматларыннан күренгәнчә, Татарстан бирелгән микрозаем күләме ягыннан 30 лидер төбәк арасында алтынчы урынга чыккан. Бишлеккә Мәскәү (128713 заем), Мәскәү өлкәсе (112721), Краснодар крае (97647), Свердловск өлкәсе (87961) һәм Башкортстан (84861) кергән.

Россиянең 3 мең микрофинанс оешмасы мәгълүматлары буенча, май аенда барлыгы 2,38 миллион заем бирелгән. Микрозаем гадәттә 30 көнгә кадәр вакыт белән 30 мең сумга кадәр рәсмиләштерелә. Шулай итеп, халык «хезмәт хакына кадәр» җәмгысы 21,59 миллиард сумлык әҗәт алып торган.

## Түләүләр билгеләнде

Республикада контракт буенча хезмәт итүчеләрдән «Алга» һәм «Тимер» батальоннары төзелде. Президент Рөстәм Миңнеханов бу батальоннарда хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган түләү турындагы указга кул куйды.

«Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операция вакытында хәрби хезмәт узучы затларга социаль ярдәм чарасы буларак 260 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә», – диелә документта.

Министрлар Кабинетына әлеге түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау күрсәтмәсе бирелде. Шулай ук республика Хөкүмәте чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә тиеш.

## *8 комлыкта ял итәргә ярамый*

Республикада пычрак комлыкларны ачыклаганнар. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе белгечләре Казанда, Чаллы, Яшел Үзән, Минзәлә һәм Кама Тамагында 8 пляжның ял итәргә яраксыз булуын билгеләгән. Соңгы мәгълүматларга караганда, Казанның «Нижнее Заречье», «Аккош күле», «Локомотив» пляжларының суы химик күрсәткечләр буенча тиешле таләпләргә туры килми. Чаллы һәм Минзәлә комлыклары да шушы исемлеккә кертелгән. Ә инде Казанның «Комсомольский», шулай ук Яшел Үзән һәм Кама Тамагы районы комлыкларына белгечләрнең микробиологик күрсәткечләр буенча дәгъвалары бар. Боларының суында эчәк таякчыгы табылган.

Шул ук вакытта, вирус, паразитлар, радиация ягыннан су чиста дип табылган. Роспотребнадзор район хакимиятләренә пычрак пляжлар суында коенуның тыелуы турында игъланнар урнаштырырга тәкъдим иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Борчыган мәсьәлә**

# Яңасы тагын да яман

**Бер ел эчендә Татарстанда наркоманнар саны 33 процентка (!) арткан. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш табиб-наркологы Резеда Хәева сүзләренә караганда, 2021 елда Татарстанда 469 кешегә «наркомания» диагнозы куелган.**

Чагыштыру өчен: алдагы елда андыйлар саны 374 булган. Хәзерге вакытта республикада наркотиклар кулланган 8 меңнән артык кеше исәптә тора. Шуларның бишесе – яшүсмер. Узган ел шушы кыек юлга кереп киткән алты үсмер исәптә торган. «Иң мөһиме – наркоманлыкның үсмерләр арасында теркәлгән яңа очраклары юк», – ди республиканың баш табиб-наркологы. Белгеч моны хәзер яшьләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып барырга тырышуы белән аңлата.

pixabay.com

Резеда Хәева сүзләренә караганда, исерткеч эчемлек, тәмәке, наркотик кебек афәтләрнең барысы да баш миенең билгеле бер өлешләренә йогынты ясый. Шул рәвешле бәйлелек барлыкка китерә. Яшьләр арасында җиңелчә генә, куркынычсыз дип саналган синтетик матдәләрнең дә зыяны әйтеп бетергесез дип чаң суга белгечләр.

– Чынлыкта теләсә кайсы заманча наркотик баш миендә төзәтеп булмаслык үзгәрешләр китереп чыгара. Алар героин кебек электән билгеле наркотиклардан да куркынычрак. Алар да кешенең психикасын җимерә, – ди Резеда Хәева.

Белгеч китергән саннардан аңлашылганча, быелның өч аенда Татарстанда 100 мең кешегә 3,7 наркомания очрагы туры килгән. Узган елның шушы ук чорында ул 2,7 очрак тәшкил иткән. «Шул рәвешле бер ел эчендә республикада наркотик кулланучылар саны 33,8 процентка арткан. Бу очраклар, нигездә, Татарстанның эре шәһәрләрендә, шул исәптән Казанда теркәлә», – ди белгеч. Әлеге афәткә бәйлелек буенча исәптә торучыларның яртысыннан артыгы (60,6 процент) – 20–39 яшьлек кешеләр. Тагын 38,4 процентын 40–59 яшьлекләр тәшкил итә.

Ел башыннан бирле республиканың хокук сакчылары 215 килограмм наркотикны кулга төшергән, Татарстанга наркотик керткән 31 канал ябылган. Әле берничә көн элек кенә хокук сакчылары Биектау районындагы бакчачылык җәмгыятьләренең берсендә эшләп яткан нарколабораториянең эзенә төшкән. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсе башлыгы урынбасары Павел Фомин сүзләренә караганда, ел башыннан бирле наркотик тарату белән шөгыльләнгән 700 кеше җинаять җаваплылыгына тартылган. Аларның күпчелеген эше, даими керем чыганагы булмаган 30 яшькә кадәрге кешеләр тәшкил итә. «Араларында 16–17 яшьлек үсмерләр дә бар», – ди Павел Фомин.

**Сүзгә-сүз**

**Александр ПЕТРОВ, Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау буенча комитеты әгъзасы:**

Читтән кертелгән товарларга бәйлелекне бетерергә кирәк. Бу – илнең дару буенча куркынычсызлыгы мәсьәләсе. Билгеле, бер генә ил дә бөтен препаратларны үзе җитештерми. Ләкин без изоляциядә түгел, безнең белән 150 илдән артык ил хезмәттәшлек итә.

**«Парламентская газета»дагы әңгәмәсеннән**

## РОССИЯДӘ – АКЧА ТУПЛАУ

**Акчаны ничек тотарга? Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан.**

## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

# *Тарих – ялгышлар җыелмасы...*

Бу атнада Бөек Ватан сугышы башлануга 81 ел тулды. Корбаннар саны буенча тарихта тиңе булмаган, безнең яктан гына да 27 млн кешенең башына җиткән ул канкоешны ничек тә булса тудырмый калыр, урап узар мөмкинлекләр булмаганмы? Европа кыйтгасында кабынып, ике дистә ел элек кенә тәмамланган Беренче бөтендөнья сугышыннан ник аз гына да сабак алынмаган? Яңа, тагын да дәһшәтлерәк үтерешнең ишек шакыганын күрмәү, аны булдырмас өчен барысын да эшләмәү, ул чор дәүләт башлыкларын, сәясәтчеләрне бизәми генә түгел, безне – бүгенге буыннарны да гаҗәпләндерә бит.

Тарих фәнендә «Фәлән чорда шундый-шундый гамәлләр кылынган тәкъдирдә, теге яки бу вакыйга яралмас иде» дигән фикер сөреше юк. Ягъни тарихчылар әйтмешли, анда шарт фигыль төркемчәсе кулланылмый. Шуңа да карамастан, шул дәвергә кайтып, сугыш алды вакыйгаларын күпмедер барлыйсы, адәми зат үзе уйлап чыгарган «сугыш» дигән фаҗиганең иң дәһшәтлесенең алшартларын карап чыгасы, булдыра алган чаклы анализлыйсы килә.

Кызыксынган кешегә узган гасырның 30 нчы еллары урталары үтүгә, дөньяда бер-берсен өнәмәгән өч полюс, өч союз барлыкка килгәнлеге мәгълүм. Болар: АКШ, Бөекбритания, Франция кергән демократик блок, Германия, Италия, Японияне берләштергән фашистик дәүләтләр альянсы һәм коммунизм тәгълиматын алга куеп яшәгән Советлар Союзы. Шушы өч союз, өч коалиция арасында катлаулы мөнәсәбәтләр булып, алар бер-берсен күзәтеп яшәсә дә, демократия илләре булсын, СССР булсын, Европа кыйтгасында яңа албасты яралуын абайламый калганнар, аның явызлыгын, амбицияләрен тиешенчә бәяләмәгәннәр булып чыга. Әллә абайларга, бәяләргә теләмәгәннәрме? Албастыга үзләре үк юл куйганнармы?

Юл кую дигәннән. Махсус эшләнмәсә дә, 1933 елда Германиядә Гитлерның властька килүендә безнең җитәкчелекнең өлеше барлыгы да билгеле. Әйтергә кирәк, фюрер хакимияткә демократик юл белән – сайлаулар аша килә. Тик ул вакытта әле аңарда беркем дә ата фашистны күрми. Дөресрәге, ата нацистны. Фашист, нацист димәктән, биредә кайбер аңлатмалар урынлыдыр. Чөнки, бик күпләр тәңгәллек билгесе куйса да, шайтан башка, җен башка, дигән кебек, ул ике төшенчә бер-берсеннән шактый аерыла. 1920 нче елларда Италиядә барлыкка килгән фашизм, аның идеологиясенең Германиядәге нацизмнан төп аермасы шунда: ул халыкларны сортларга бүлми, анда расачыл теория юк. Анда, әлбәттә, беренче урында дәүләт, аның мәнфәгатьләре, әлбәттә, диктатура һәм юлбашчы культы. Халык, кайсы гына милләт вәкиле булуына да карамастан – икенчел. Вә ләкин аны яхшы-начарга бүлү юк. Нацизмда (националь-социализмда) исә беренче урында дәүләт түгел, ә супермилләт – немецлар. Калган барлык милләтләр дә – кеше булып җитешә алмаган түбән сортлы кавемнәр. Алар йә юкка чыгарылырга, йә югары сортлы милләткә хезмәттә торырга тиеш. Бу – Гитлер хакимияткә ирешкәч тә немец халкына тоташ сеңдерелә башлаган һәм сеңдерелгән тәгълимат.

1933 ел, безнең гаеп, безнең өлеш, дигәндә шул: «халыклар атасы», Коминтерн аша, немец коммунистларын андагы социал-демократлар белән бер коалиция төзеп, ул сайлауларда берләшеп катнашудан тыя. (Имештер ки, Германиядәге 1918 елгы революция дә нәкъ менә социал-демократлар аркасында үз максатларына ирешә алмаган.) Нәтиҗәдә тегеләре дә, болары да күпчелек тавыш җыя алмыйча, җиңеләләр. Властька «Майн кампф» (Россиядә экстремистик материаллар исемлегенә кертелгән. – **Ред.**) авторы – «җенле ефрейтор» килә. Ә коммунистлар социалистлар белән берләшкән һәм җиңгән булса?

Утызынчы елларда СССРда тулы көченә индустриализация бара. Корал да коела. Тик икътисад хәрби рельсларга күчте, диярлек дәрәҗәдә түгел. Ә менә Германия – Беренче бөтендөнья сугышын башлаган һәм җиңелгән ил, аны танклар, сугышчан самолетлар, башка төрле һөҗүм кораллары ясаудан тыйган 1919 елгы Версаль килешүен бозып, милитаризация юлына инде баскан була. Шул Килешүгә кул куйган Англия, Франция, АКШ, башкалар ни караган? Хәтта Гитлер суверен Австрияне Германиягә кушып, Чехословакиянең Судет өлкәсен аннекцияләгәч, Польшага ымсына, Гданьск портын сорый башлагач та, бернинди нәтиҗәләр ясалмый. Киресенчә, Бөекбританиянең ул чордагы премьеры Чемберленны искә төшергәндә, күбрәк «агрессорны тынычландыру, аның тамагын туйдыру» сәясәте хакында сөйләү урынлы. Гомумән дә Европа илләре җитәкчеләре арасында 1939 елның көзенә кадәр – асларына су керә башлаганчы – «Германия үз тирә-ягындагы вак, көчсез дәүләтләрне йотып куяр да тынычланыр, безгә кагылмас» дигән фикер өстенлек итә. Шул рәвешле яңа явызлыкларга юл куела. 1938 елгы хурлыклы Мюнхен килешүен – Англия, Франция, Италия лидерларының, җыйнаулашып, без әйткән Судетны, зәңгәр каймалы тәлинкәгә салып, фюрерның өстәленә китереп куюын аңлау хәзер дә кыен. Шул чакта бергәләшеп, кая үреләсең, дип баш нацистның кулына суккан булсалар...

Булсалар, булса... Тарих – ялгышлар җыелмасы шул. Икенче яктан, ул – лидерларның, ил җитәкчеләренең шахмат уены. Тик уеннардан күп вакыт уймак чыга. Шундый уймакларның тагын берсе – Германия белән СССР арасындагы үзара һөҗүм итешмәүне күздә тоткан 1939 елгы Молотов – Риббентроп пакты. «Халыклар атасы» өчен АКШ, Бөекбритания, Франция – барысы да, үзе әйтмешли, «черек демократия» илләре. Ни өчен черек? Чөнки аларда халык фикере белән исәпләшү бар. Ә ул дөрес түгел. Андый строй, андый эчке сәясәт – властьның көчсезлеге, зәгыйфьлеге билгесе. Бит элек-электән хакимият – җил, халык – үлән. Ничек шуны аңламаганнарга ышанмак, ничек таянмак, алар белән ничек берләшмәк кирәк! Нәкъ менә шундый мантыйк Сталинны ул пактка этәрә дә. Польшаны урталай бүлдергән, Балтыйк буе дәүләтләрен СССРга кушкан, Фин сугышын башлаткан килешүгә. Һәм ахыр килеп, булачак генералиссимусны төп башына утырткан, 1941 елның җәендә аны алдаячак дуслыкка.

Бүген яхшы беләбез: СССРга соңарып булса да «черек демократияләр» белән союзга керәсе, алардан дүрт ел буе ленд-лиз дип аталган глобаль ярдәм алып торасы, шашкан фюрерны җыйнаулашып җиңәсе булачак. Коточкыч сандагы корбаннар биреп. Ә Совет иле шул ук 1939 елда, Германия урынына аркадаш итеп, аңа әзер Бөекбритания белән АКШны сайлаган булса? Фюрер сугыш уты кабызырга базмас, сугышкан очракта да муенын тизрәк сындырган булыр иде бит...

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

# КҮПЕРГӘ ТУЗАН ТӨШМӘС

tatarstan.ru

**Бу көннәрдә Татарстан белән Якутия арасындагы күпер тагын да ныгыды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация Саха (Якутия) Республикасына сәфәр кыла. 22–25 июньдә биредә Татарстан Республикасы көннәре уза. Хәтерләсәгез, былтыр Татарстанда Якутия көннәре үткән иде. Кунак ашы – кара-каршы.**

### Эшләгәнгә – эш

Рөстәм Миңнеханов Саха Республикасы башлыгы Айсен Николаев белән очрашуда бу көннәрнең хәтердә якты истәлек булып калуын искәртте. Якутиядә Татарстан көннәренең дә әнә шундый рухта узуына өмет белдерде. «Якутия – бүген иң тиз һәм нәтиҗәле үсештә булган төбәкләрнең берсе. Республика казанышлары – якутларның тырыш хезмәт нәтиҗәсе», – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов соңгы елларда ике төбәк арасындагы товар әйләнешенең 4 миллиард сумга җиткәнлеген искәртте. «Без нефть, газ эшкәртү, машина, судно төзелеше, авыл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек итәргә телибез», – диде Президент. Очрашуда мәгълүматлаштыру һәм заманча техника юнәлешендә дә хезмәттәшлек итү турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов Якутия вәкилләрен Kazan Digital Week халыкара цифрлы форумына чакырды. Президент җирле татарларга теләктәшлек күрсәткәне өчен Айсен Николаевка рәхмәт сүзләре дә җиткерде. Бүген анда 8 меңнән артык милләттәшебез яши.

«Безнең узган елгы сәфәр яхшы нәтиҗә бирде. Икътисад тармагында да, мәдәният юнәлешендә дә бик зур эшләр башкарыла», – диде Айсен Николаев. Төбәк башлыгы сүзләренә караганда, Якутия IT-продуктларны экспортлау буенча ил төбәкләре арасында 9 нчы урынга чыккан. Ике төбәк арасында хезмәттәшлек өчен дә яхшы юнәлеш дип атады ул аны. «Безнең авыл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәттәшлек өчен дә мөмкинлекләр зур. Татарстаннан бик күп белгечләр килде. Безгә сезнең бу юнәлештәге тәҗрибәгез кызыклы», – диде Якутия башлыгы. Ул газ ягулыгы тармагы белән дә кызыксынуларын искәртте. Айсен Николаев якын киләчәктә Якутиядән Казанга туры рейслар оча башлаячагына да өмет белдерде.

### Очрашу урыны – сквер

Очрашудан соң Айсен Николаев белән Рөстәм Миңнеханов танылган якут язучысы Платон Ойунский һәйкәленә чәчәк салды. Бу көнне Якутиядә татарлар өчен дә мөһим урын барлыкка килде. Анда «Казан» скверына нигез салынды. «Барлык ватандашлар өчен дә мөһим вакыйга бу, чөнки Саха (Якутия) Республикасы башкаласында татарлар өчен әһәмиятле җир – якташлар очрашуы, мөһим чаралар уздыру урыны барлыкка килә. Ул безнең республикалар һәм тугандаш халыклар арасындагы дуслыкны ныгытуга яңа этәргеч булсын», – диде Рөстәм Миңнеханов. Яңа скверда татар шагыйре Муса Җәлилгә һәйкәл куелачак.

Эшлекле сәфәр барышында Рөстәм Миңнеханов Якутия татарлары белән дә очрашты. «Сезнең белән очрашуга бик шатмын. Татарстаннан читтә яшәсәгез дә, милли гореф-гадәтләрне, туган телне, мәдәниятне, йолаларыбызны саклыйсыз, – диде Рөстәм Миңнеханов татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре белән очрашуда. – Татарстан казанышларында Саха (Якутия) Республикасы белән сәүдә-икътисади хезмәттәшлек мөһим урынны алып тора. Бүген имзаланган килешүләр безнең төбәкләр арасында хезмәттәшлекне тагын да көчәйтәчәк». Очрашу ахырында Президент «Татарларда кунакта» күргәзмәсе белән дә танышты.

### «Тамырларыбыз бер»

Якутиягә сәфәр барышында ике төбәк арасында мөнәсәбәтләр сүздә генә түгел, документлар белән дә беркетелде. «Татарстан – Якутия» форумы кысасында өч килешү имзаланды. Аерым алганда, «Ак Барс» судно төзү корпорациясе» белән «Жатайская судоверфь», «Химград» Технополис» индустриаль паркы белән Саха (Якутия) Республикасы Хөкүмәте, «Саха-Рэм» җаваплылыгы чикләгән җәмгыяте белән Саха (Якутия) Республикасы хөкүмәте арасында хезмәттәшлек турында килешүләргә кул куелды. Форум кысасында Якутия һәм Татарстан муниципалитетлары арасында да хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Айсен Николаев бу килешүнең әһәмиятле булуын искәртте.

Рөстәм Миңнеханов ике арадагы элемтәләрнең тагын да ныгыячагына ышаныч белдерде. «Саха (Якутия) Республикасы – күптәнге, әһәмиятле хезмәттәшебез. Төбәкара товар әйләнеше елдан-ел арта бара. Татарстаннан йөк машиналары, шин, ягулык китерелә», – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Россиядәге этиленның – 25,6 проценты, синтетик каучукның 41,5 проценты Татарстанда җитештерелә. Илдә чыккан һәр ике машина шинының берсе, һәр өч йөк машинасының берсе бездә ясала. Ул ике республика өчен дә икътисади, шул исәптән кече һәм урта бизнес вәкилләре белән дә элемтәләр мөһим булуын искәртте.

Татарстан Президенты әйтүенчә, зур компанияләр белән икътисади элемтәләр мөһим, әмма кече һәм урта бизнес та биредә үз урынын табарга тиеш. Без Якутия Республикасының ни дәрәҗәдә ачык булуын күрәбез. Без – Якутиядә, ә Якутия бизнесы Татарстанда булсын өчен, бездә дә шундый ук шартлар тудырачакбыз. Бу – төп бурыч», – диде Рөстәм Миңнеханов.

> Президент сүзләренчә, ике республиканы мәдәни һәм хәтта туганлык җепләре бәйли. «Нигездә, тамырларыбыз бер. Без – туганнар. Без туганнарга килдек һәм аларны Якутиянең 100 еллыгы, уңышлары һәм нәтиҗәләре белән котлыйбыз, – диде ул. – Бер-беребездән өйрәнерлек нәрсәләр күп. Иң мөһиме: без – милли республикалар: үзенчәлегебезне, телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне сакларга кирәк. Иртәгә сезнең яраткан бәйрәмегездә катнашу һәм бераз гына сезгә милли бәйрәмебез Сабантуйны күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлекләребез бар. Ә сезнең һәм безнең бәйрәмне берләштерсәк, бездән дә бәхетлерәк беркем булмаячак!»

### Якутскида – утырыш

Көн дәвамында Рөстәм Миңнеханов Айсен Николаев белән бергә, видеоконференция элемтәсе режимында Верхоянск шәһәрендә гибрид электр станциясен файдалануга тапшыруда да катнашты. Верхоянск Якутскидан 700 км төньякта урнашкан һәм Җир йөзендә иң салкын урыннарның берсе санала. Аны еш кына төньяк ярымшарның Салкын полюсы дип тә атыйлар. Бүген шәһәрдә 1100 кеше яши. Верхоянскида гибрид электр станциясен «ЭНЭЛТ» төркеме төзегән. Әлеге компанияләре төркеменә Казан һәм Зеленодольск шәһәрләрендәге ике җитештерү мәйданчыгы да керә. «ЭНЭЛТ» оешмасында барлыгы 300 кеше эшли. Шуларның 200е Татарстанда хезмәт куя.

Рөстәм Миңнеханов Якутскида Россия Инновацион төбәкләре ассоциациясе утырышын уздырды. Видеоэлемтә буенча анда Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин да катнашты. «Хәзер ассоциациягә илнең 18 төбәге керә. Алар өлешенә Россия инновацион продукциясенең өчтән бере туры килә», – диде Татарстан Президенты. Соңгы дүрт ел эчендә ассоциациягә Новгород өлкәсе, Саха (Якутия) Республикасы, Түбән Новгород өлкәсе, Ханты-Манси автономияле округы да кушылган. «Саха Республикасының ныклы үсешен билгеләп үтәсем килә. Якутия эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыра, илнең Арктик зонасын үстерү өчен, югары технологияле суднолар җитештерә, Ерак Көнчыгыш федераль округында иң цифрлашкан төбәк булып тора», – диде Рөстәм Миңнеханов. Марат Хөснуллин ассоциация эшчәнлегенең мөһим булуын искәртте. «Бу бигрәк тә хәзер, икътисад үсешенең яңа юлларын эзләгәндә мөһим. Сез туплаган тәҗрибәне таратырга кирәк. Һәр төбәкнең диярлек үз инновацион эшләнмәләре бар, аларны өйрәнергә һәм ил буенча кертергә кирәк. Хәзер без юл төзелешен биш еллык планлаштыруга күчәбез. Мин барлык төбәкләргә үсеш программаларын әзерләгәндә иң яхшы тәҗрибәләрне кертергә тәкъдим итәм. Алар соңыннан бөтен Россия буенча таралачак», – диде ул.

# БАЛЛЫ ҖӘЙ... БАЛЛАНАМЫ?

**Быелгы соңга калган яз, җәй умартачыларны борчуга салмаганмы? Җәйге сезон баллы булырмы? Арча районында күпләп бал кортлары агуланган, сәбәп нидә? Балтач районының иң тәҗрибәле, танылган умартачыларының берсе – Түбән Кенәдән Айдар Сәмигуллин белән умартачылыктагы мәшәкатьләр турында сөйләшәбез.**

Айдар Сәмигуллин турында без инде берничә тапкыр яздык. Үз хуҗалыгында күпләп терлек асрап, ул бер елны «Россиянең иң яхшы 100 хуҗалыгы» дипломына лаек булды. Ул чакта дуңгызчылык белән шөгыльләнде. Бераздан мөгезле эре терлеккә күчте, савым сыерлары алып җибәрде. Бу юнәлештә дә шактый танылды. Аннан инде әтисеннән мирас булып калган берничә оя умарталарын берничә дистәгә җиткерде. Терлек асрау белән параллель алып барса да, анысын да аксатмады, умартачылыкта да Балтач брендына әйләнгән балы белән республикада, аннан читтә танылу алды. Булганнан бар да була, дисәң дә, Айдар үзе әле дә, умартачылыкта барысын да белеп бетермим, дип саный. Юкса бу юнәлеш белән һөнәри шөгыльләнә башлавына да уникенче ел.

**:: Быелгы язы, җәе соңлаган елда кортлар – балсыз, маллар печәнсез калыр дип курыкмыйсызмы?**

– Уйландыра инде. Бөтенесе соңга калды бит. Яз бал кортлары өчен уңай килмәде. Минем үземнең 2010 елдан бирле мондый ел күргән булмады, тәҗрибәле умартачылар, гомергә мондый язны, җәй башын күргән юк, диләр. Ачлыктан оя-оя кортлары үлеп беткән кешеләр дә булган. Шөкер, безнекеләр әйбәт кышлады. Үлем-китем өч процент тирәсе генә булды. Бу – бөтенләй юк дигән сүз инде. Кышлатуга килгәндә, без кортларны өйгә кертмибез. Тышта, кар белән күмеп калдырабыз. Кар астында салкынлык 5–6 градустан артмый, шуңа күрә салкын кыш та аларга зыян салмый. Март азагында исә, чаңгы белән менеп, кардан чистартабыз, территориягә көл сибәбез, үзебезчә ревизия ясыйбыз.

**:: Кортларны урманда, кар астында калдыру куркыныч түгелме соң? Кыргый, ач җанварлар һөҗүм итсә...**

– Беренче ел гына шулай эшләмибез инде. Шөкер, әлегә кадәр тыныч булды.

**:: Кортлар әйбәт кышласын өчен, көздән нинди чаралар күрәсез?**

– Көздән һәр ояда 20 килограмм чамасы азык калдырабыз. Шуннан да аз калдырсаң, алар кышны бик көчсезләнеп чыга, чөнки ояда 2–2,5 килограмм корт кала, ә бер килограммга ун мең корт керә. Кышны алар азыкка кытлык сизмичә, тыныч үтәргә тиеш. Безнекеләр ашап та бетермәгән иде, әмма барыбер, язга чыгуга, тагын ашаттык. 75 процент шикәр пудрасын бал белән болгатып, бераз су кушып, камыр формасында азык куйдык һәм аксымга бай өстәмәләр дә бирдек. Көннәр җылытуга, ояларны юып, кортларны чиста ояларга күчерәбез. Җылы көннәр булганда төрле кушылмалар, әйтик, соя онына, кызыл ачы борыч, коры сөт болгатып куябыз (кортлар аларны чәчәк серкәсе урынына, балаларына ашатырга дип, ояга ташый), берәр стакан май аенда үскән әрем, чәчәк аткан чакта җыелган әрем, мәтрүшкә, нарат бөресе, ачы кызыл борыч салып кайнатып, бер литр шикәр сиробына 100 грамм исәбеннән әлеге төнәтмәне кушып бирәбез, җилсез, гел кояш төшкән урынга табакка су салып, азрак диңгез тозы кушып, кортларны шуннан су эчәргә ияләштерәбез. Аларга ризыктан тыш су да кирәк. Батып үлмәсеннәр өчен, табак төбенә печән яки салам салабыз.

**:: Кечкенә генә кортларга әллә ниләр кирәк икән... Мәшәкате шактый...**

– Шулай эшләмәсәң, җәй көне бал алам димә. Кортларны июльгә кадәр карыйсы, ашатасы. Быел июнь аенда, мәсәлән, көн саен 800 грамм – бер килограмм бал ашаттык. Бал җыю чоры бер ай. Ярый әле, май – июнь айларында өчәр көнләп булса да, җылы, матур көннәр булды. Кортлар талга оча алды. Үткән ел тузганакка очмаганнар иде, быел аннан да бал җыйдылар. Өрәңге, алмагачка да очтылар... Күп булмаса да, бераз бал ала алдык. Соңгы ике көндә кортлар бик әйбәт эшли. Тәҗрибәле бер умартачы көндәлек алып бара. Аның сынамышы буенча, 25 гыйнварда көн матур булган, быел бал булачак, ди ул. Өметләнәбез инде. Без үзебез бал гына түгел, бал икмәге (перга), балавыз, аңардан мазь һәм төнәтмә дә ясап сатабыз, башка төрле төнәтмәләребез дә бар, аларны балга караганда да күбрәк сорыйлар, чөнки һәркайсы – бик күп чирләргә дәва. Хезмәтләребез җилгә очмасын, өметләр аклансын иде инде.

**:: Шушы көннәрдә күрше Арча районында бик күпләп бал кортлары агуланган дигән хәбәр таралды. Кортлар нилектән агулана? Моны булдырмас өчен нәрсә эшләргә кирәк?**

– Кортлар кыр-басуларны агу-химикатлар белән эшкәрткәннән агулана, үлә. Агуларның да бит төрлесе бар. Куркынычлыгы өч дәрәҗә белән билгеләнә. Еш кына җитәкче-белгечләр арзанлы агу-химикатлар белән эшли, әмма тикшерү килгәндә, «Без менә шушындый куркынычсыз химикатлар белән генә эшлибез», – дип күрсәтергә үзләрендә нормаль агу-химикатларны запаста тота. Нәтиҗәдә гаеплеләр ачыкланмый да кала. Шөкер, бу яктан безнең районда мондый хәлләр күзәтелгәне юк. Социаль челтәрдә махсус төркем бар, шунда агулау-эшкәртү көннәре турында кисәтүләр алдан языла.

**:: Җәйләрегез баллы булсын.**

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

## УКУЧЫ СҮЗЕ

vk.com

## Тик синең өчен, балам!

*– Нилектән, йөгерек чишмәкәй,*
*Шифалы көмеш суың?*
*– Туган җирнең куеныннан*
*Башлана минем юлым.*

*– Нилектән җиләк-җимешең*
*Авызда эри, урман?*
*– Туган җирдә үскән алар,*
*Шунлыктан татлы булган.*

*– Нилектән болын-кырларда*
*Күңелгә шатлык алам?*
*– Туган җирнең бар ямьнәре*
*Тик синең өчен, балам!*

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

## Тарих сабагы

Тарих кабатлана, диләр. Узган елдагы корылык йөз ел элек булган күренешне кабатлады. 1921 елда май аеннан июль ахырына кадәр яңгыр яумаган. Август аенда гына яңгырлар була башлагач, җирдә үлән типкән. Фән, техника үсү аркасында, корылык булса да, без быел ачлык дәрәҗәсендә калмадык. Ә менә барлык хуҗалыклар да бура төбенә өмет итә алмады. Тарихи тәҗрибә шуны раслый: бураңда бер елдан артыкка җитәрлек ризык тотмасаң, алдагы көнеңә ышанма. Бу бигрәк тә терлек асраучы авыл халкына кагыла. Авыл халкының актык икмәген тартып алу аяныч нәтиҗәләргә китерде дә инде.

Тарихта шунысы мәгълүм: 1860 ел Көнбатыш Европа дәүләтләре өчен бик авыр чор була. Җәй буе туктаусыз яңгырлар ява, киптергән печән череп бетә, бодай, солы август аенда да өлгерә алмый. Дәүләтләр бер-берсенә ярдәм итү хәлендә булмый. Фәкать Россиянең көньяк өлешендә булган икмәккә генә өмет итәләр. Илебез халкы 1891 елны да бик авыр кичерә. Корылык нәтиҗәсендә, ачлык үзенең колачын җәя. 1910–1911 елларда да корылык була. 1936 ел Татарстанда шулай ук корылык елы булып санала. Хәтта саранчалар да барлыкка килә.

Безнең гаилә дә ачлыктан интегә. Әтинең энесе Гаптелбәр абый ай саен Казаннан капчыклап ипи алып кайта торган була. Ә колхозның барлык икмәген дәүләткә тапшырып бетерәләр. Бер шундый кызыклы хәл дә була. Минем әни, инешкә суга төшкәч, көянтә-чиләкләрен ташлап, юкка чыга. Авыл халкы шау итә: Гаптелхакның хатыны, имеш, чиләкләрен ташлап качкан икән. Дөрес, әти табып алып кайта әнине. Олыгая төшкәч, мин, нигә ташлап качтың чиләкләреңне, дип әнидән сорадым.

– Улым, мин качмадым, ачлыкка чыдый алмагач, әтиләргә таба йөгердем, ашарга аз-маз борчактан башка берни юк иде, – диде әни.

Колхоз оештырып, бабайлар яшәгән яңа төзелгән авылда ачлык ул кадәр үк көчле булмаган, күрәсең, буралары да тирәнрәк булгандыр.

Илебезгә немецлар басып кергән айларда Татарстанда гөрләп иген үсә. Учмада килеш яңгыр астында яткан икмәкне күреп, әтиләребез сугышка күз яшьләре белән китәләр. Ирләрсез, көчсезләнеп калган авылларның икмәк җыеп алырга хәлләреннән килми. Әле җыеп алынганы да фронтка китә. Барлы-юклы бәрәңгене дә киптереп җыялар. 1942 елның кышкы салкыннары – Россия тарихында үзе бер могҗиза. Авылларда да, шәһәрдә дә ягарга юк, булган утыннар паровозларга китеп бара. Бакчалардагы җиләк-җимеш агачлары суыкка чыдый алмыйча корыйлар.

1950–1951 елларда да корылык булып алды. Ә менә 1972, 1974 еллардагысы турында аерым әйтми булмый. Мари урманнары шул елларда янды бит. Тирә-юньне төтен басты. Хайваннарга ашатырга саламны Казахстаннан ташыдык. Ә алдагы елларда саламны ут төртеп яндырганнар иде. 1975, 1991, 2001 елларда да корылык булды. Икмәк тә, бәрәңге дә юньләп уңмады. 1976 елда иген уңса да, җыеп ала алмадык. Урак өстендә яңгырлар китте. Җирдәге ашлык череп ятты. Иң хәтәре 1981 ел булгандыр, мөгаен. Җәй көне дә юньләп үсмәгән бәрәңге көз көне бакчада ук череп ятты. Татарстан хөкүмәте Польша белән дуслыкка кереп, балчыкка чумган бәрәңгене шуннан кайтартты. Бәрәңге белән бергә Польшадан колорадо «дуңгызы» ияреп килде.

2010 ел турында әйтеп тә торасы юк: Мәскәүне төтен басты. Икмәк тә, бәрәңге дә уңмады. Әмма язгы чәчүне вакытында башкарып, көздән чәчкән арыш-бодайны игътибар үзәгендә тоткан хуҗалыклар авыр хәлдән чыга алдылар. Капитализм урнашу чорында, сугару өчен файдаланылырга тиешле алюминий торбалар урланып, сатылып бетерелгәч, печән, яшелчә кытлыгы барлыкка килде. Терсәк якын, әмма тешләп булмый. Белоруссиядән ялынып алып кайткан бәрәңге файда бирмәде. Минем күршеләрем уникe капчык бәрәңге алып калганнар иде, бер айдан череп бетте.

Үткәндәге вакыйгалар күпме кисәтсә дә, без табигать үзгәрешләренә битараф карыйбыз. Булган арышны, бәясе түбән дип, урмыйча калдыру җинаять саналырга тиеш. Әле узган җәйдә дә, саламны ваклап, җиргә чәчеп калдыру күренешләре булды. Ашлык мул булган елларны комбайннар җитешми, кызурак йөргән комбайннар ашлыкны сугып бетерә алмыйлар. Бу тиз йөрешле чит ил комбайннарына хас. Димәк, безгә табигатьтән генә мәрхәмәт көтеп утырырга түгел, үзебезгә алдан аяк киенергә кирәк.

Әнис ЗАРИПОВ.
Казан

## Гәүдәләр турая иде

Остазыбыз Фоат Галимуллинны еллар узган саен ныграк сагынабыз. Аудиториягә Фоат абый килеп кергәндә, ерык авызлар җыела, йокысы туймаган студентларның гәүдәләре турая иде. Аның көр тавышы күктән җиргә тиз төшерергә сәләтле булды. Фоат абыйның дәресләренә бик яратып йөрдек. Төркемдәшләр белән очрашканда, аны гел яратып искә алабыз. Кайбер сыйфатларын исебездә тотабыз. Фоат абый сәгать ярымлык лекцияне, бер дә дәфтәргә, китапка карамыйча, матур итеп сөйләде. Ул юмор хисе булган үтә дә җитди кеше, гадел, тирән белемле һәм дә таләпчән, үз эшенең остасы булды. Аның кебек сөйләүче һәм тавышлы кеше башка юктыр.



vk.com

**Фоат абыйның шәкерте, якташы Нурфия Халикова язган шигырьне укучыларыбыз хозурына да юллыйбыз.**

*Кукмара таулары белә,*
*Хәтерлиләр тавышын.*
*Яшь чагыннан сөйләп үсә,*
*Дөрес сайлап үз юлын.*

*Сөендерә халкын һәрчак*
*Сөйләме тыныч, җылы.*
*Тапшырулар вакытында*
*Тыңлап туймыйлар аны.*

*Һәр чыгышы уйланылган,*
*Төпле фикер, туры сүз.*
*Чал тарихны күргән сыман*
*Аны тыңлаганда без.*

*Тирән фикер иясе ул,*
*Галим фән өлкәсендә.*
*Көр тавышы яңгыраган*
*Илебез киңлегендә.*

*Таң калып тыңлата белә*
*Үзенең сүзе белән.*
*Күңелләргә үтеп керә*
*Матур җырлары белән.*

*Таләпчән дә, гаделлеге*
*Игътибар үзәгендә.*
*Әдәбият, милләт, диеп*
*Янып яши бүген дә.*

*Яхшы тәнкыйтьче, остаз ул,*
*Шәкертләр өчен тиңсез.*
*Якташым, горурлыгыбыз,*
*Рәхмәт сүзебез чиксез.*

Казан дәүләт педагогика университеты татар филологиясе факультетының 2005 ел чыгарылыш студентлары

# ТАЯНЫЧЫМ

Бу 1954 ел иде. Беркөнне төш күрәм. Эштән кайттым, имеш, ә өйдә ашарга бер нәрсә дә юк. Куркып уянып киттем. Хәер, күп уйланып йөрергә туры килмәде, Нәҗип килеп керде. Ул елмаеп кына: «Күптән әйтәсе килгән сүземне әйтергә килдем. Әйдә, бергә булыйк. Өйләнешик!» – ди. Мин гаҗәпкә калдым, ни диярга дә белмәдем. Ә ул: «Нигә шулкадәр аптырап калдың, без бит инде күптәннән бер-беребезне беләбез, яшебез дә җиткән», – ди. Мин аңа: «Ашыккан ашка пешкән, диләр бит, уйлашыйк әле», – дидем.

Беләм, әни каршы килмәс, чөнки ул аны гел мактап, якын күреп йөри иде. Икенчедән, егет минем күңелемә игелекле булуы белән дә кереп калган. Бервакыт шулай үткәннәр турында сөйләшеп утырабыз. Ул, үкенеп: «Сезнең шундый авыр тормышта яшәгәнегезне белмәдем шул, шахтадан посылкалар салган булыр идем», – дигән иде. Шул вакытта аның сүзләре мине посылка алганнан да ныграк шатландырды. Чөнки мин үземнең ниндидер бер таянычым бар сыман хис иттем. Әтисез ятим үскәнгә, йөрәк ярама бер тамчы дару салган кебек булган иде ул. Өченчедән, ялгышмаммы, дигән сорау да борчый. Озакка сузып тормадык: сөйләштек-уйлаштык та, ике якның да ризалыгын алып, өйләнешергә булдык.

Сөйләшү буенча, Нәҗип мине иртәнге сәгать 4тә ат белән килеп алырга тиеш. Фанерадан ясалган бер бәләкәй яшел сандыгым бар иде, шуңа бирнә әйберләремне тутыра башладым. Ситсыдан теккән чаршау, аннан чәчкәләп-чәчкәләп чиккән җәймә, аның өстеннән караватка җәяргә бәйләнгән челтәр, биш тәрәзәгә биш пәрдә, берничә сөлге салдым һәм ике яңа мендәр бәйләп куйдым. Хаҗип абыйсы белән килеп, мине үзләренә алып кайтып киттеләр. Анда безне каенатам Фәләхетдин, каенанам Факиһә һәм каенсеңлем Камилә каршы алдылар. Өйгә килеп керү белән тәмле аш, коймак исләре борынга килеп керде. Беренче күрүдә үк алар – мине, мин аларны үз иттем һәм гомер буе шулай яшәдек. Ашагач, эчкәч, әти барыбызга да карап: «Балалар, бүген безне бик күп эшләр көтә. Аллаһы теләсә, сезгә бүген никах укытырбыз, ЗАГСка да барып кайтырсыз», – диде. Без: «Әмин», – дидек. Язылышып кайтканда, өйгә тәмле бәлеш исләре таралган иде инде. Озак та үтмәде, ашка кешеләр җыела башлады, мулла да килеп җитте һәм безгә никах укыдылар.

Менә шул вакытлардан соң бергә яшәвебезгә бик күп еллар үтте. Ике малай, бер кыз үстердек. Балалар хәсрәте күрмәдек.

Миңзифа ХӨСНЕТДИНОВА.
Әлмәт

# ШӘҺӘРДӘН КАЙТКАННАР

Зәй районының Карман авылы клубында үзешчәннәр Галиәсгар Камалның «Беренче театр» спектаклен сәхнәгә куйдылар. Алдан ук шуны әйтеп куйыйм: үзешчәннәр дигәнебез – яшь арасы 57дән алып 69га кадәр булган, барысы да диярлек туган авылларына әйләнеп кайткан шәһәр пенсионерлары. Үзем дә шулардан иҗат көче, яшәү дәрте алып кайттым әле.

Әлеге чара районның 370 еллыгына багышланган фестиваль кысасында үткәрелгән иде. Анда катнашкан авылдашлар көтелмәгән яктан ачылды да куйды. Районның мәдәният йорты җитәкчесе Гүзәлия Гатина, пьесаны сәхнәләштергән клуб җитәкчесе Рамилә Мөхәсимованың эшенә югары бәя биреп, образларның дөрес бирелүен, сәхнәнең заманасына туры китереп бизәлүен, киемнәрнең зәвык белән сайлануын, артистларның рольләрен нечкәлекләрне истә тотып уйнауларын ассызыклады.

Җырлап-биеп кенә яшәми шәһәр пенсионерлары. Ниндидер бер талпыну белән дәррәү кайтып төште алар Карманга. Туган нигезләрен яңартып, тавык-чебеш, кәҗә-сарык асрап көн күрәләр. Икенче сулышы ачылган ярышчыдай, тормышның тәмен, вакытның кадерен белеп яшиләр. Эш тәмамлангач, авыл клубында җыелырга сәбәп чыгып кына тора. Я бер бәйрәмгә, я икенчесенә әзерләнергә кирәк. Клубның сәнгать җитәкчесе Фирдания Ханнанова әйтүенчә, бүген алардан башка авылда бер генә чара да узмый. Чишмә торгызырга кирәк булсынмы, мәчеткә ярдәм итәргәме, Сабан туен оештырыргамы – ир-атлар шундук җиң сызганып тотына.

Безнең халыкның, яшем җиткән инде дип, үзен дөнья эшләреннән чикләп куя торган гадәте дә бар. Кайберәүләр катнашу түгел, әзер чараны килеп карарга да ирендәләр. Йөрәк типкәндә, кул-аяк йөргәндә яшәргә кирәк әле! Карман халкы – ул яктан искиткеч җиңел халык. Әнә бит авылның иң өлкән кешесе, яше туксаннан узган тыл хезмәткәре Роза апа Хәкимҗанова спектакль карарга килгән, иң беренче рәттә утыра!

Карманга кайткан шәһәр пенсионерлары, чыннан да, олыгаеп килгән авылдашларыбыз тормышына яңа сулыш өрде. Җылылык, сөю хисләре таратып яшәү үзе рәхәт бит!

Фирдәүсә БИКМӘТОВА.
Казан

# ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘҮЧЕЛӘР

**Язмамның герое – Фәйрүзә. Хәер, алай гына түгел, бу гаилә бер йодрык булып яши. Авылда аларның ярдәме тимәгән кеше юктыр.**

Фәйрүзә Балыклы авылында бик күркәм гаиләдә туып-үскән. Әтисе Хашим абый белән әнисе Фатыйма апа озак еллар кибеттә сатучы булып эшләделәр. Ул чорда кибетчегә 70 кг авырлыктагы капчыкны күтәрәсе, авыр ящикларны ташыйсы бар, кибет салкын, халыкның бөтенесенә ярарга кирәк. Кибетче булу куркыныч та иде, буталчык еллар бит. Ничек чыдаганнардыр?

Фәйрүзәнең тормыш иптәше Фиргать – әтисеннән яшьли калып, тормышның бөтен авырлыкларын ялгызы җиңеп, бары хәләл, авыр хезмәт белән, бүгенге җитеш тормышны үз куллары белән булдырган егет. Аның йорт-җиренең төзеклеген күрсәң, хәйран калырлык! Әйләнеп чыга алмассың. Халык сүзе белән әйтсәк, аталардан бала яшьли калса, күкрәк көче белән мал таба. Иртә яздан кара көзгә кадәр тракторда: сукалау, печән чабу, пресслау, бәрәңге утырту, казу, тагын күп төрле хезмәт. Ару-талуны, ялны белмичә, җәй буе йокы күрмичә, авыл халкына хезмәттә ул. Кышкы көндә дә тракторын ремонтлап, тәртипләп тота, техниканы гына түгел, тимер эшләрен дә яхшы белә, үзе башкара. Авылда булып торган иң фаҗигале хәлләрнең берсе – янгыннар. Фиргать анда да, иң беренчеләрдән булып, техникасы белән ярдәмгә ашыга. Карап торуга аз сүзле, кырыс булып күренсә дә, юморга бай, бер кешенең үтенечен кире какмый, күрше-тирәсенә генә түгел, бөтен авылга бик ярдәмчел кеше ул. Авылда иң зур вакыйга – мәрхүмне соңгы юлга озатудан калмый, ләхет алырга да авырсынмый. Әнисе Хәтимәне дә бик олылап, кадерләп яшәде алар.

Үзләре кебек ярдәмчел, акыллы ике бала тәрбияләп үстерделәр. Икесе дә югары белемле. Уллары Илнар район үзәгендә эшли, әтисе кебек тырыш, кулыннан килмәгән эше юк. Кызлары Ләйсән Казан дәүләт медицина университетын тәмамлап, Саба районының Шәмәрдән үзәк хастаханәсендә эшли. Бистә халкының гына түгел, тирә-як авыл кешеләренең дә ихтирамын яулый. Тәҗрибәле табибәнең безнең авыл кызы булуы, эш сәгатеннән соң төп йортка, әти-әнисе янына кайтуы – авыл халкы өчен зур бәхет. Райондагы участок терапевтына барып күренү, киңәшләрен алу бик катлауланды. Беренчедән, чиратка язылып көтү бик озак. Икенчедән, авыру кешегә, бигрәк тә олы яшьтәгеләргә район хастаханәсенә бару – үзе бер зур проблема.

Ләйсән эштән арып кайтуына карамастан, авылдашларын кире бормый, ярдәм итәргә тырыша. Кирәкле даруларны да алып кайта, дәвалау барышын күзәтеп, алга таба нишләргә кирәклеген аңлатып бирә. Аңа елый-елый рәхмәт әйтүчеләр дә бар. Шундый тынгысыз эш көненнән соң өйдә аны шатлыгы – Нәфисәсе көтеп тора. Еракта яшәүче оныклар да каникул көннәрен, озын ялларны санап, көтеп кенә торалар. Әби-бабай янындагы рәхәтлекне беләләр.

Фәйрүзәнең абыйсы озак еллар Олыяз урта мәктәбе директоры булды. Шактый еллар бергә эшләдек. Кабатланмас шәхес иде ул. «Алтын йөрәкле кеше» исемен алуы да, «Россиянең иң яхшы кешеләре» энциклопедиясенә кертелүе дә юкка түгел. Ул барында мәктәптә спорт секцияләре эшләп торды, спорт бәйрәмнәре, ярышлар үткәрелде. Гомәр үзе дә бу чараларда кайнады, балалар янында булды. Шифаханәләргә юлламалар тапты. Укучыларны Мәскәү, Болгар, Казанның тарихи урыннарына экскурсияләргә алып барды. Атаклы шәхесләр Әсгать Галимҗанов, Фатих Кәрим кызы Ләйлә ханым, Ренат Харис, Фоат Галимуллин, Рәзил Вәлиев белән очраштырды. Фәнис Яруллин, Рәниф Шәриповның өйләрендә булдылар…

Мәктәпкә академик Альберт Борһанов, атаклы шәхес Валерий Черепанов, профессор Илгизәр Әхмәтов, Австрия рәссамы Сафия Вәлиеваларны чакырды. Олыяз мәктәбе гөрләп торды ул вакытларда.

1991 елдан укучыларны туплап, Үлем үзәнендә казу эшләрендә булуы да балаларга патриотик тәрбия бирү максатыннан иде. Иң зур хезмәте – авылларның «Хәтер» китапларын язу, Зөлхәбирә Якупова белән Туган якны өйрәнү музее булдыру. Музей хәзер бик хаклы рәвештә аның исемен йөртә.

Авылда Фәйрүзәнең апасы Фәридә дә гаиләсе белән яши. Ераграк күршем Мәдинәнең болай дип сөйләгәне хәтердә калган: «Ирем Альберт төнлә каты авырый башлады. Фельдшер чакырттык. Шунда ук больницага барырга кушты. Әйтүе генә ансат. Ә кеше каян табарга? Машина юк. Читенсенеп кенә Фәридәләргә киттем, хәлемне аңлаттым. Фәридә, хәзер Ильясны уятам, алып барыр, үзең дә утырып бар, синсез булмас, ди. Өйдә өч бала, сыер. Үзем карармын, кайгырма, ди. Үзенең дә өйдә балалары, терлеге, иртән эшкә. Менә шулай, акча да алмадылар, аларның ярдәмен һич онытмыйм», – диде.

Кешеләргә яхшылык эшләр өчен туган алар бу җиргә. Барлык авылдашлар да шундый фикердә.

Рәсимә СӘЛАХОВА.
Кукмара районы Олыяз авылы

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «2023елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 июнь. № 33-ТРЗ

## «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау – авыл хуҗалыгы җирләренең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес мәгълүмат алуга юнәлдерелгән күзәтүләр, бәяләү һәм фаразлау системасы.»;

2) 3 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында» 1998 елның 16 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында күрсәтелгән федераль дәүләт бюджет учреждениеләре авыл хуҗалыгы җирләреннән файдалану һәм аларның торышы турында, шул исәптән әлеге статьяның өченче абзацы нигезендә авыл хуҗалыгы җирләрендә үткәрелгән туфрак, геоботаник һәм башка тикшеренүләр нәтиҗәләре хакында, белешмәләр тапшыралар;»;

б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар мондый җир кишәрлекләре урнашкан авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр алырга;»;

в) бишенче һәм алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы һәм җиденче абзац дип санарга;

3) 7 статьяның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәпкә алуын, гамәлгә ашыру;»;

4) 12 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәпкә алуын, гамәлгә ашыру;»;

5) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. **Авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау**

Авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау җирләрне дәүләт тарафыннан мониторинглауның состав өлеше була һәм федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6) түбәндәге эчтәлекле 15[1] статья өстәргә:

«15[1] статья. **Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестры**

Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестры авыл хуҗалыгы җирләренең торышы турында, алардан файдалану хакында системалаштырылган дөрес белешмәләр җыелмасыннан гыйбарәт.

Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрын алып бару федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белешмәләрне җыюны, гомумиләштерүне һәм аларны авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрына тапшыруны гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 июнь. № 34-ТРЗ

## Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек (алга таба – бакчачылык һәм яшелчәчелек) белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге вәкаләтле органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

3) гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе (алга таба – бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе) чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез алу тәртибен раслау;

4) коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәте (алга таба – ширкәт) әгъзаларының гомуми җыелышын үткәрү турында хәбәр урнаштырылырга мөмкин булган массакүләм мәгълүмат чараларын билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү;

2) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру;

3) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү мәсьәләләре буенча федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү;

4) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 2 өлешендә ширкәт әгъзалары санына карата билгеләнгән таләп үтәлмәгән очракта, ширкәтне бетерү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме**

1. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үз структурасында гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итү буенча республика сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче бүлекчәләр төзергә;

2) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шул исәптән инвестиция программаларын, кабул итәргә;

3) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүен популярлаштыру максатларында агарту эше алып барырга;

4) бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык һәм электр энергиясе, су, газ белән тәэмин итүне, су җибәрүне, ягулык белән тәэмин итүне оештырырга;

5) чикләрендә бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре урнашкан кадастр кварталларына карата комплекслы кадастр эшләрен үтәүне финанслауны башкарырга;

6) бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәт Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт милкендә булырга мөмкин булган очракта, ширкәтнең яисә мондый гомуми файдаланудагы мөлкәткә гомуми өлеш милкендә катнашучыларның гаризасы буенча мондый гомуми файдаланудагы мөлкәтне (автомобиль юллары, электр челтәре хуҗалыгы объектлары, су белән тәэмин итү объектлары, элемтә объектлары һәм башка объектлар) Татарстан Республикасы дәүләт милкенә түләүсез алырга;

7) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүне Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә башкарырга.

2. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтелә.

3. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә әлеге статьяның 1 өлешендә каралган дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Чикләрендә бакча җир кишәрлекләрен һәм яшелчә җир кишәрлекләрен бары тик чираттан тыш, беренче чиратта яисә башка ташламалы сатып алу хокукы булган гражданнар гына ия булган мондый җир кишәрлекләре урнашкан бакчачылык һәм яшелчәчелек территорияләренә карата дәүләт ярдәме чаралары өстенлекле тәртиптә күрсәтелә.

7 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме принциплары**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт ярдәменең адреслылыгы һәм максатчан характерга ия булуы;

2) дәүләт ярдәменнән бертигез дәрәҗәдә файдалана алу;

3) дәүләт ярдәме күрсәтү процедураларының ачыклыгы;

4) дәүләт ярдәменең финанс чараларын һәм башка чараларын бергә алып бару;

5) дәүләт ярдәмен, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп, күрсәтү.

8 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм**

1. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнарында каралган рәвешләрдә гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм күрсәтергә хокуклы.

2. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән күрсәтелә.

3. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру тәртибе җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

9 статья. **«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясының үз көчен югалтуын тану**

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2, (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 июнь. № 35-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 2 өлешенең 6 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «энергетика» сүзеннән соң «һәм торба үткәргеч транспорт» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасы өстәргә:

«д) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать оешмаларын һәм башка оешмаларны газлаштыруның расланган региональ программасында каралган төп магистральгә ялганган газүткәргечләр һәм газ бүлү станцияләре;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 июнь. № 36-ТРЗ

## «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «ике проценттан» сүзләрен «10 проценттан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының даими маршрут буенча хәрәкәтенә махсус рөхсәт, шул исәптән электрон рәвештә, гадиләштерелгән тәртиптә бирелә.»;

3) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 июнь. № 37-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

21 июнь, 2022 ел Казан ш. № 173/1535

**2022 елның 11 сентябрендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә гражданнарның сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» 12 июнь, 2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 47 статьясындагы 7, 8 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 57 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсе тапшырган 2022 елның 11 сентябрендә 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы буенча, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә өчен төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеген (кушымта итеп бирелә) 2022 елның 26 июненнән дә соңга калмыйча «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

2. Бу карарны һәм 2022 елның 11 сентябрендә 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы буенча, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә өчен төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеген Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Скврдяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тапшырды

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 21 июнь, 2022 ел, № 173/1535 карарына кушымта

**2022 елның 11 сентябрендә 7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы буенча, 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын өстәмә сайлауны үткәргәндә төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеге**

**7 нче Ибраһимов бер мандатлы сайлау округы 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округы**
**Дәүләт төбәк телерадиотапшырулар оешмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Телерадиотапшырулар оешмасы атамасы | Әлеге оешма чыгара торган массакүләм мәгълүмат чарасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын (телеканал, радиоканал, телепрограмма, радиопрограмма) тарату формасы | Телевидение тапшыруларына, радио тапшыруларына лицензия нигезендә, массакүләм мәгълүмат чарасын тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Телерадиотапшырулар оешмасының юридик адресы | Телерадиотапшырулар оешмасының гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының устав (җыелма) капиталындагы өлеше (кертеме) | Оешма эшчәнлегенә федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре төре | Оешма эшчәнлегенә федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме | Тиешле телеканалның, радиоканалның (телепрограмма, радиопрограмма) махсус булып тору-тормавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | ВГТРК ФГУП филиалы – «Татарстан» ГТРК | Россия радиосы | Радиоканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 76123 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 2. | ВГТРК ФГУП филиалы – «Татарстан» ГТРК | «Россия» (Россия-1) телеканалы | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 76122 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 3. | ВГТРК ФГУП филиалы – «Татарстан» ГТРК | «Россия-24» (Россия-24 с) Россия мәгълүмат каналы | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 48108 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 4. | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниесе» акционерлык җәмгыяте | «Татарстан-Яңа Гасыр» радиосы | Радиоканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 79339 | 02.11.2020 | 420095, Казан ш., Шамил Усманов ур., 9 й. | «Таиф» ААҖ, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 48,421% | Субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | - |
| 5. | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниесе» акционерлык җәмгыяте | «Татарстан-Яңа Гасыр» телевидениесе | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 79341 | 02.11.2020 | 420095, Казан ш., Шамил Усманов ур., 9 й. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 48,421% | Субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | - |

**Төбәк вакытлы матбугат басмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Вакытлы матбугат басмасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык нигезендә, тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Вакытлы матбугат басмасы редакциясенең юридик адресы | Вакытлы матбугат басмасының, басма матбугат редакциясенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының устав (җыелма) капиталындагы өлеше (кертеме) | Оешма эшчәнлегенә Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре төре | Оешма эшчәнлегенә Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме | Вакытлы матбугат басмасын чыгаруның ешлыгы | Вакытлы матбугат басмасының махсус булып тору-тормавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | Ватаным Татарстан | Татарстан Республикасы (Татарстан), шулай ук татарларның Россиядә (Татарстан Республикасы (Татарстан) тупланып яшәү урыннары | № 430 | 21.06.1995 | 420097, Татарстан Республикасы, Казан ш., Академия ур., 2 й. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты; «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты | 100% | субсидияләр | - | атнага 4 тапкыр | - |
| 2. | Республика Татарстан | Татарстан Республикасы (Татарстан), шулай ук татарларның БДБдә (Татарстан Республикасы (Татарстан) тупланып яшәү урыннары | № 429 | 21.06.1995 | 420097, Татарстан Республикасы, Казан ш., Академия ур., 2 й. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты; «Редакция газеты «Республика Татарстан»; Татарстан Республикасы дәүләт бюджеты учреждениесе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 100% | субсидияләр | - | атнага 4 тапкыр | - |
| 3. | Казанские ведомости | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ФС 7 - 4671 | 30.11.2007 | 420066, Татарстан Республикасы, Казан ш., Чистай ур., 5 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | 100% | субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | атнага 4 тапкыр | - |
| 4. | События недели. Казань | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ТУ 16 - 01162 | 13.02.2014 | 420066, Татарстан Республикасы, Казан ш., Декабристлар ур., 2 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | 100% | субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | атнага 1 тапкыр | - |

**Муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Телерадиотапшырулар оешмасы атамасы | Әлеге оешма чыгара торган массакүләм мәгълүмат чарасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын (телеканал, радиоканал, телепрограмма, радиопрограмма) тарату формасы | Телевидение тапшыруларына, радио тапшыруларына лицензия нигезендә, массакүләм мәгълүмат чарасын тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Телерадиотапшырулар оешмасының юридик адресы | Телерадиотапшырулар оешмасының гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталда муниципаль берәмлекләрнең өлеше (кертеме) | Оешма эшчәнлегенә җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре төре | Оешма эшчәнлегенә җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме | Тиешле телеканалның, радиоканалның (телепрограмма, радиопрограмма) махсус булып тору-тормавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

**Муниципаль вакытлы матбугат басмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Вакытлы матбугат басмасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык нигезендә, тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Вакытлы матбугат басмасы редакциясенең юридик адресы | Вакытлы матбугат басмасының, басма матбугат редакциясенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталда муниципаль берәмлекләрнең өлеше (кертеме) | Оешма эшчәнлегенә җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре төре | Оешма эшчәнлегенә җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме | Вакытлы матбугат басмасын чыгаруның ешлыгы | Вакытлы матбугат басмасының махсус булып тору-тормавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре: күчемсез милеккә кадастр бәяләве уздыру бүлеге башлыгы урынбасары **Җаббаров** Равил Нил улына, дәүләт җир күзәтчелеге, геодезия һәм картография бүлеге башлыгы **Кыямов** Алмаз Әхтәм улына, Лениногорск бүлеге башлыгы **Сафина** Алсу Әхмәт кызына, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» филиалы хезмәткәрләре: баш бухгалтер **Петрухина** Альбина Раил кызына, китап цехының өлкән мастеры **Садриева** Мәшкүрә Сәлим кызына, басу цехының яссы басма печатнигы **Фәтхенурова** Рәзилә Зәйнулла кызына, җитештерүне тәэмин итү департаменты буяучысы **Фоминова** Нина Ивановнага, механика хезмәте механигы **Фурманов** Вадим Гершоновичка, китап цехының брошюралаучысы **Ярхәмова** Гөлия Хәкимҗан кызына, Татарстан Республикасының Теләче муниципаль районы «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Иске Җөри авыл мәдәният йорты директоры **Насыйбуллин** Равил Мөсәвир улына, «Казанның психик авырулары булган гражданнар өчен интернат-йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе табиб стоматологы, социаль-тернәкләндерү бүлекчәсе мөдире **Яковлева** Ольга Александровнага, «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыятенең Әлмәт район нефть үткәрү идарәсе башлыгы **Гәрәев** Азат Мөрсәлим улына; «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыяте генераль директорының персонал белән идарә итү һәм гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Кашапов** Рушад Роберт улына; «Иннополис» махсус икътисади зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Хаҗиәхмәтов** Булат Зөфәр улына, «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры киңәшчесе **Конева** Екатерина Илдар кызына, «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасының хокукый мәсьәләләр буенча директоры **Сафина** Дания Дамир кызына, «Иннополис» акционерлык җәмгыятенең юридик бүлеге башлыгы **Лазарева** Юлия Вячеславовнага, «Иннополис» акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры **Романова** Марина Илфат кызына, «Иннополис» акционерлык җәмгыяте генераль директорының эксплуатация буенча урынбасары **Сабирҗанов** Ирек Рәшит улына, «Күшәр» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Галиәхмәтов** Илнар Илдар улына, «Тукай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча техникы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Гарипов** Габделхай Габделбари улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте баш киңәшчесе **Воронина** Юлия Владимировна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе урынбасары **Газиев** Наил Хәмит улы; республикада социаль сәясәтне тормышка ашыруга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе **Захарова** Светлана Михайловна; мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Россия суд эшчәнлеге дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе Казан филиалы директорының административ-хуҗалык эше буенча урынбасары (Казан шәһәре) **Миңнебаева** Гөлсәрия Илдус кызы; «Солнечный» балалар бакчасы автоном коммерциячел булмаган мәктәпкәчә белем бирү оешмасы директоры **Миңнегалиева** Фирдәүс Гаязетдин кызы; банк системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционерлык коммерциячел банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) Хокукый тәэмин итү дирекциясе директоры **Ощепков** Андрей Александрович; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Кукмараагрохимсервис» акционерлык җәмгыяте директоры **Тимофеев** Валерий Федорович; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Буа шәһәр прокуроры **Фәткуллин** Марс Расыйх улы; инвалидларга социаль ярдәм күрсәтүне оештыруга өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» инвалидларның бөтенроссия иҗтимагый оешмасы Татарстан төбәк оешмасы белгече **Хуҗина** Алсу Кәрим кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Россия Саклык банкы» гавами акционерлык җәмгыятенең 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлекчәсе куркынычсызлык идарәсе икътисади куркынычсызлык бүлегенең алдап урлашу җинаятьләренә каршы көрәшү секторы өлкән белгече **Исмәгыйлев** Динар Бакый улы, хезмәт ветераны **Лисенкова** Любовь Александровна, хезмәт ветераны **Нуретдинова** Гөлсинә Әхәт кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – психиатр-наркологы **Әхмәдуллина** Нурия Шәйдулла кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эпидемиология бүлеге табиб-эпидемиологы **Шәфикова** Резеда Алмаз кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе дәвалау-профилактика учреждениеләре эшчәнлегенә күзәтчелек бүлеге башлыгы **Алёшина** Анна Геннадьевнага, «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды» дәүләт учреждениесенең медицина ярдәменең сыйфатын контрольдә тотуны оештыру идарәсе башлыгы **Доронина** Людмила Александровнага, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе туклану гигиенасына күзәтчелек бүлеге өлкән белгече **Сингатуллина** Гүзәлия Хәмит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Торак-коммуналь хуҗалык системасын үстерүгә, Казан шәһәрен төзекләндерүгә һәм агачлар-үсемлекләр утырту эшенә өлеш кертүләре өчен Казан шәһәренең «Горводзеленхоз» су һәм агачлар-үсемлекләр утырту хуҗалыгы буенча шәһәр производство тресты» муниципаль унитар предприятиесе хезмәткәрләре: җитештерү-техник бүлеге башлыгы **Бицура** Надежда Константиновнага, «Питомник» участогы башлыгы **Гыйльфанов** Илфат Шәрифҗан улына, механикалаштыру базасы филиалы башлыгы **Нурисламов** Фәннур Нурсәеф улына, «Шәһәр урман паркы» участогы башлыгы **Шәрәфиев** Дамир Әхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

# ЕВРАЗИЯ ТАТАРСТАННАН ӨЙРӘНӘ

## РЕСПУБЛИКАНЫҢ ҖИР ЭШКӘРТҮ ЮНӘЛЕШЕНДӘ БАШКАЛАР БЕЛӘН УРТАКЛАШЫРЛЫК ТӘҖРИБӘСЕ БАР

**Казанда «Евразия интеграциясе – 2022» халыкара конгрессы булып узды. Россия Дәүләт Думасының БДБ эшләре, Евразия интеграциясе һәм ватандашлар белән бәйләнешләр комитеты, Татарстан Дәүләт Советы, Татарстан Фәннәр академиясе, республиканың икътисад җәмгыяте тарафыннан Россия ирекле икътисади җәмгыяте катнашында оештырылган мәртәбәле чарада бүгенге шартларда уртак эш турында сөйләштеләр.**

Конгрессның пленар утырышында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин галимнәрне һәм конгресс кунакларын республика җитәкчелеге исеменнән сәламләде, Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавровның һәм БДБ илләре Парламентара ассамблеясы советы генераль секретаре Дмитрий Кобицкийның котлауларын да җиткерде.

Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Вадим Хоменко җитәкчелегендә сугарулы игенчелек шартларында биопродукция җитештерү мәсьәләләренә багышланган фәнни-гамәли конференция Конгресстагы төп вакыйгаларның берсе булды. «Татмелиоводхоз» федераль идарәсе белән берлектә Лаеш районының Нармонка җирлегендә оештырылган күчмә утырышта галимнәр һәм белгечләр «түгәрәк өстәл»гә җыелып, «Евразия икътисади берлеге (ЕАЭС) һәм БДБ илләрендә органик авыл хуҗалыгын үстерү һәм экологик чиста продукция җитештерүгә теләктәшлек итү хакында фикер алышты.

Конгресста катнашучылар Россия Фәннәр академиясенең Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының (ТатНИИСХ), Казан дәүләт аграр университетының Агробиотехнопаркы һәм «Татмелиоводхоз» идарәсенең сугарулы тәҗрибә кырларында булып, андагы эш нәтиҗәләрен үзләре барып күрде. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Татмелиоводхоз» идарәсе директоры Марс Хисмәтуллин һәм ТатНИИСХ директоры Рөстәм Низамов мелиорацияне үстерү буенча тәҗрибә мәйданнарында эшнең барышы белән таныштырдылар.

Марс Хисмәтуллин билгеләп үткәнчә, республикада өйрәнү-тикшеренү эшләрендә кыр сынаулары аеруча зур роль уйный. Тотрыклы нәтиҗәләргә ирешү ниятеннән бу эшләр инде 10 ел буена өзлексез алып барыла. Шушы максатларда өч мәйданда – ТатНИИСХ, Казан дәүләт аграр университетының Агробиотехнопаркы һәм «Казан-Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге кырларында заманча проектлаштырылган сугару системалары төзелгән. Мәйданнарда мелиорациянең төрле ысуллары һәм нормалары шартларында сугарулы игенчелек һәм үсемлекләр селекциясе өлкәсендә фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәрелә. Төрле алымнар һәм технологияләр сынала. Моннан тыш, республиканың тармак хуҗалыкларында сугару буенча тәҗрибәләр үтә. Бәрәңге үстерү, үсемлекчелек, яшелчәчелек һәм җиләк-җимеш культураларының иң уңышлысын сайлап алу өчен зур эш башкарыла.

«Түгәрәк өстәл»нең модераторы, икътисад фәннәре докторы Вадим Хоменко билгеләп үткәнчә, мондый мәртәбәле чарада катнашучыларның әлеге мәйданнардагы эш тәҗрибәсен өйрәнүе ике як өчен дә отышлы. Татарстан мелиораторларының коллегалары белән уртаклашырлык уңышлары бар. Республикада сугарулы игенчелектә инновацион эшләнмәләрне фәнни яктан тәэмин итү һәм кулланышка кертү буенча зур эш башкарылды, ул сугарулы җирләрне ел саен кимендә 5 мең гектарга арттыра барырга мөмкинлек бирә.

Бүген Татарстан җирләрне сугару буенча Россиядә алдынгылар рәтендә. Соңгы 10 елда мелиорация буенча федераль һәм республика максатчан программалар кысаларында тармакка 8 млрд сумнан артык инвестицияләр җәлеп ителгән, 32 мең гектардан артык сугарулы җир файдалануга тапшырылган, 467 гидротехник корылма торгызылган, 30 мең гектар мәйданда урман полосасы утыртылган. Ел саен 80 мең гектар сөрүлек җирләрдә известьләштерү эшләре үткәрелә.

Республиканың тагын бер өстенлеге – Казан сугару техникасы заводында җитештерелгән заманча сугару техникасын куллану. Татарстанда җитештерелүче биопрепаратларны файдалану исә пестицидлар куллануны киметергә һәм шуның нәтиҗәсендә экологик чиста продукция алырга мөмкинлек бирә.

Аграр университет ректоры Айрат Вәлиев «түгәрәк өстәл»дә катнашучыларны университетның заманча лабораториясе белән таныштырды. Аның сүзләренә караганда, биредә туфракны һәм үсемлекләрне җентекләп тикшерү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Шулай итеп, Татарстанның яңа сортларны, заманча технологияләр, сугару һәм туфрак эшкәртү техникасын гамәлгә кертү буенча уникаль тәҗрибәсе бар. «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар геосәяси шартлар үзгәреп торган бүгенге заманда азык-төлек иминлеге, финанс һәм икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү өчен мелиорация һәм экологик чиста продукция җитештерүдә ЕАЭС илләренең көчләрен берләштерергә, шулай ук Татарстан тәҗрибәсен Россиянең башка төбәкләрендә дә гамәлгә кертергә тәкъдим иттеләр.

Марсель ХИСМӘТУЛЛИН

# ТУРЫ СҮЗЛЕ, ӘЧКЕРСЕЗ

**«Холкы җиңелләрдән булмады, әмма төгәл һәм әйтәсе фикерен кистереп әйтә белде». Сәясәтче, депутат, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Сибагатуллинны аны якыннан белүчеләр әнә шулай дип искә ала. Аның йөрәге җомгага каршы төндә тибүдән туктады. Фатыйх Сибагатуллинга 72 яшь иде.**

«Татар-информ»

1990 нчы еллар башында Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгын җитәкләгән, Нурлат районының элеккеге башлыгы, Дәүләт Думасында өч чакырылыш дәвамында депутат булган шәхес республиканың яңа тарихында зур эз калдырды. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул эштә булды һәм үзен киңкырлы шәхес буларак танытты.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та, мәрхүмнең хатыны Рәдифә Сибагатуллинага телеграмма юллап, аны иң тәҗрибәле җитәкчеләрнең берсе дип атады.

«Ул – Татарстанда иң тәҗрибәле һәм абруйлы җитәкчеләрнең берсе иде, гомер буе туган җиренә тугры һәм нәтиҗәле хезмәт иткән, республиканың күп кенә районнарын үстерү өчен, гомумән, агросәнәгать комплексы һәм Татарстан икътисады потенциалын арттыру өчен күп эш башкарган кеше. Россия Дәүләт Думасында Фатыйх Сәүбән улының күпьеллык актив эше республикадагы иң актуаль мәсьәләләрне хәл итүгә дә, Россия дәүләтен ныгытуга да зур өлеш кертте. Бу көчле рухлы, хезмәт сөючән кеше һәрвакыт эшкә җаваплы карашы һәм билгеләнгән максатларга ирешә белүе белән аерылып торды, ул үзе янында эшләгән һәркемгә көчле иҗади дәрт һәм энтузиазм өстәде. Фатыйх Сәүбән улын белгән һәркем хәтерендә ул Татарстанның чын ватанпәрвәре, бай һәм якты тормыш белән яшәгән тынгысыз иҗатчы буларак калыр дип ышанам», – дигән Президент.

Мәрхүмнең якыннарының авыр кайгысын Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да уртаклашты. Аның сүзләренчә, Фатыйх Сибагатуллин белән эшләү бәхетенә ирешкән һәркем аны хезмәт сөючәнлеге, дәрт-дәрманы ташып торуы, тотынган эшне ахырына кадәр җиткерүе, сәләтле, киң эрудицияле һәм киләчәкне күрә белүе өчен хөрмәт итә һәм бәяли.

– Фатыйх Сибагатуллин талантлы һәм күпкырлы шәхес, татар халкы тарихы буенча күп кенә китаплар һәм тикшеренүләр авторы буларак та безнең хәтеребездә калачак. Фатих Сәүбән улының вакытсыз үлеме – аның туганнары һәм якыннары өчен генә түгел, ә безнең республикада яшәүчеләр өчен дә авыр югалту. Аның турында якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр! – диде парламент башлыгы.

Татарстан Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров та талантлы җитәкченең арабыздан китүен республика өчен зур югалту дип бәяли.

«Көчле рухлы шәхес, талантлы җитәкче һәм авыл хуҗалыгын оештыручы, зур профессионал арабыздан мәңгегә китте. Бу – республика өчен дә бик зур югалту, чөнки Фатыйх Сәүбән улы бөтен тырышлыгын, тәҗрибәсен, белемен, күңел җылысын, көч-куәтен, үзен аямыйча, Татарстанны үстерүгә багышлады. Безгә аның күпкырлы эшчәнлеге җимешләре мирас булып кала. Янәшәсендә эшләргә насыйп иткән, аны белгән һәркем бу шәхеснең гаять көчле холкы-фигылен, ирләрчә нык сүзен һәм күңел көрлеген онытмаячак», – диелә мәрхүмнең хатыны Рәдифә ханымга юллаган телеграммада.

Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов Фатыйх Сәүбән улы белән бергә эшләгән елларын искә алды.

– Мин аны Мамадышта эшләгән чорыннан бирле беләм. Соңгы елларда исә аның белән янәшә утырып эшләдек. Ул авыл хуҗалыгы министры булганда да юлларыбыз еш кисеште. Чаралар уздырганда гел ярдәм итә иде. Ул шул вакыттан ук үзен төгәл кеше итеп күрсәтте. Булдырасын булдыра, булдырып булмастаен ышандырмый иде. Беренче тапкыр Яшьләр форумын уздыруны да үз өстенә алды. Ул чакта да эшлекле һәм игътибарлы була белде.

Илдар Гыйльметдинов сүзләренчә, элеккеге депутатны туры сүзле кеше буларак искә алачаклар:

– Әйе, холкы җиңелләрдән булмады. Аның белән аралашып китү җиңел генә булмаска да мөмкин иде. Ләкин ул төгәл һәм үз фикерен курыкмыйча әйтә белде. Бу сыйфаты Мәскәүдә эшләгәндә аеруча нык чагылды. Ул күп тапкыр республиканы яклап чыгыш ясады. Гомумән, Фатыйх Сәүбәнович киңкырлы шәхес иде. Сәясәтче булса да, тарих белән бик нык кызыксынды. Укымышлы, гыйлемле кеше булды. Татарлар тормышын чагылдырган тарихи китаплар бастыру буенча зур эш алып барды. Шуңа күрә аңа һәркем, аксакал итеп, хөрмәт белән карый иде. Авыл хуҗалыгын да аның кебек яхшы белгән кешеләр сирәк. Аның өчен экология дә мөһим булды, проектларны тормышка ашыру юнәлешендә эшләде. Кешеләрне тыңлый белде. Дәрәҗәсе булса да, үзен башкалардан өстен куймады.

«Татарстан муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин белән алар бер уку йортында укыганнар, бер командада көрәшкәннәр. Соңыннан да бер сукмактан атлаганнар:

– 1991 елда ул мине Татарстан авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары итеп чакырды. Бу елларда һәрвакыт аның профессиональлегенә игътибар итә идем. Эшлекле, тырыш булганлыктан, министрлыктагы эшен бик акыллы һәм лаеклы итеп оештыра белде. Ул безнең агросәнәгать комплексы үсеше өчен бик күп эшләде. Нәкъ менә ул эшләгән елларда Татарстанда авыл хуҗалыгы буенча яңа технологияләр барлыкка килде. Аны Казанда гына түгел, районнарда да бик яхшы беләләр, чөнки Балтач, Арча, Мамадыш һәм Нурлат районнары өчен күпне эшләде. Намуслы, үз эшенә бирелгән кеше булды. Хезмәттәшләре арасында да абруе зур иде. Шәхсән үзем өчен Фатыйх Сәүбәнович профессиональ һәм кешелекле, бөтен мәсьәләдә дә үз фикере булган уникаль җитәкче һәм сәясәтче буларак истә калачак.

Фатыйх Сибагатуллин белән Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында хушлаштылар. Аны туган ягы – Арча районының Апаз авылында җирләделәр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

**Матбугат әһелләренең дә якын дусты, киңәшчесе, фикердәше иде ул. Фатыйх Сәүбәновичтан тәнкыйть сүзе ишетү дә үзе бер дәрәҗә булды. Димәк, язманы укыган, битараф түгел. Фикерләрен, моны әйтсәм ярармы икән, ярамасмы, дип тормый, шартлатып әйтә: саллы, дәлилле итеп.**

Тарих белән бик нык кызыксынды. Кая гына барса да, китаплар төяп кайтуы да мәгълүм, аларны таныш-белешләренә, бөтенләй таныш булмаганнарга да укырга биреп тора, аннан фикерләрен белешә, бәхәсләшеп алган чаклары да була.

Шәхсән минем үземә Фатыйх Сәүбәнович Россия Дәүләт Думасы депутаты чорында Мәскәүдә депутатлар яшәгән йортта кунак булу бәхете дә тиде. Депутатларны Думага махсус автобуслар алып бара икән. Депутатлар автобуслар килеп туктауга ук урын алырга ашыкмый, шулай гадәткә кергән: Фатыйх Сәүбәновичның кайсы автобуска утырачагын күзәтәләр, аннан инде аның белән бергә автобуска күтәреләләр. Фатыйх Сәүбәнович шундук микрофонны үз кулына ала һәм тарих диңгезендә йөздерә башлый, әлбәттә инде, татарлар, милләтебезнең үткәне, бүгенгесе турында сүз булмыйча калмый.

Фатыйх Сәүбәнович рус һәм татар телләрендә тарихыбызга мөнәсәбәтле бик күп китаплар да нәшер итте. Яшь буын үткәнен белергә, шуңа нигезләнеп киләчәген билгеләргә тиеш, дигән фикердә иде ул. Ел саен туган авылында – Арча районындагы Апаз урта мәктәбендә очрашулар үткәрү дә шул нияттән иде. Быелгы очрашу да бик эшлекле, дустанә үтте. Укучылар авылдашларын сорауларга күмделәр, сәләтләрен дә күрсәттеләр. Фатыйх Сәүбәнович, кайда гына чыгыш ясаса да, мәңге онытылмас хатирәләр калдырды, аның турындагы истәлекләр дә хәтердән һич җуелмас.

Габделбәр РИЗВАНОВ

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

## СИБАГАТУЛЛИН ФАТЫЙХ СӘҮБӘН УЛЫ

**(01.05.1950 – 24.06.2022)**

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Күренекле дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтче Сибагатуллин Фатыйх Сәүбән улы 24 июнь көнне 73 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Фатыйх Сибагатуллин 1950 елның 1 маенда ТАССР Кызыл Юл районы (хәзерге Арча районы) Апаз авылында дөньяга килә. 1973 елда – Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария институтын, 1987 елда – Саратов югары партия мәктәбен, 2005 елда – В.В. Куйбышев исемендәге Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый. Ветеринария фәннәре докторы, профессор булды.

Фатыйх Сәүбән улы үзенең хезмәт эшчәнлеген 1966 елда ТАССР Арча районы «Ватан» совхозында эшче буларак башлап җибәрә. Югары белем алганнан соң, Яшел Үзән районы «Бишнә» совхозында, Балтач районы «Чапаев» колхозында баш ветеринария табибы булып эшли. 1976 елда Балтач районы «Правда» колхозы рәисе була. 1980–1991 елларда Балтач, Арча һәм Мамадыш районы җирле хакимият органнарында, партия оешмаларында җаваплы вазыйфалар били.

Фатыйх Сибагатуллин 1991 елда – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп, 1995 елда – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп билгеләнде. Фатыйх Сәүбән улы әлеге вазыйфаларда эшләү чорында авыл хуҗалыгы буенча инновацион чаралар эшләп, гамәлгә кертте. Алар ашлыктан югары уңыш җыеп алу һәм республикада терлекчелек өчен мул азык базасын булдыру мөмкинлеге бирде. Агросәнәгать комплексының техник тәэмин ителешен модернизацияләү буенча зур эшләр башкарылды.

Фатыйх Сибагатуллин 1996–2007 елларда Татарстан Республикасы Нурлат районына җитәкчелек итте. Аның җитәкчелегендә районда югары социаль-икътисади күрсәткечләргә ирешелде, авыл хуҗалыгы эзлекле төстә үстерелде, район ашлык җитештерү буенча алдынгылыкка чыкты.

Фатыйх Сибагатуллин ТАССР Югары Советы депутаты, ТАССР халык депутаты, I, II чакырылышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, V–VII чакырылышларда Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты итеп сайланды. Ул авыл хуҗалыгын үстерү өлкәсендә күп кенә закон проектлары тәкъдим итте, федераль үзәк белән республика дәүләт хакимияте органнары арасында нәтиҗәле үзара мөнәсәбәтләр урнаштыруда актив катнашты.

Фатыйх Сәүбән улы фәнни эшчәнлек белән актив шөгыльләнде. Ул ветеринария хезмәтен камилләштерү, мөгезле эре терлекнең токымын яхшырту юнәлешендә күп көч куйды. Россия академияләре һәм халыкара академияләр әгъзасы, шул исәптән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире булып торды. Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты булды.

Фатыйх Сибагатуллин татар халкының тарихын, аның тикшеренү эшләрен аерым бер кызыксыну белән өйрәнде. «От Атиллы до президента», «Мифы и легенды», «Великие татары – строители и защитники государства Российского», «Татары и евреи» әсәрләре халык арасында аеруча нык танылды.

Фатыйх Сибагатуллинның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Почет, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» IV дәрәҗә, Халыклар дуслыгы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре», «Татарстан Республикасының атказанган экологы» дигән мактаулы исемнәр, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы.

Фатыйх Сибагатуллин максатка омтылучан, талантлы оештыручы, игътибарлы һәм кешелекле остаз булды. Тормышта актив позициядә торуы, ватанпәрвәрлеге, иҗтимагый бурычка, эшенә тугрылыгы белән аерылып торды.

Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинның – уникаль язмышлы кешенең – якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, М.А.Җәббаров, А.З.Фәррахов, М.Г.Әхмәтов, Ә.С.Гобәйдуллин, И.Р.Метшин, А.С.Әхмәтшин, А.П.Иванов, И.Г.Нуриев, М.Х.Сәлахов, Р.Х.Равилов.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, өч чакырылышта Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, Татарстан Республикасы элекке Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Нурлат районы элекке хакимияте башлыгы

**Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИНның**

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Саба муниципаль районы Советы, башкарма комитеты һәм район халкы, күп еллар республикабызда җитәкче урыннарда эшләгән, РФ атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, элекке Дәүләт Думасы депутаты

**Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИНның**

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгыларын уртаклаша.

Сарман муниципаль районы советы һәм башкарма комитеты,

**Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИН**

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы агрокомплексы ветераннар Советы Президиумы, республика халык хуҗалыгын үстерүгә биниһая зур өлеш керткән шәхес

**Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИН**

73 нче яшендә вафат булу сәбәпле, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Аның эшчәнлеге туган төбәгендә – Арча, Балтач районнарында башланды һәм республика күләмендә дәрәҗәле җитәкче, галим буларак танылу алды, халкыбызга армыйталмый хезмәт итте. Авыр туфрагы җиңел булсын!

Әйдә, халыкка хезмәткә!

# Эшкә өндәү

**Гомерләрен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган шәхесләр белән элемтәне өзмәскә, алар турында яшь буынга сөйләргә, хезмәтләрен үрнәк итеп, безне һәм безнең дә эшкә өндәргә. Әнә шундый нияттән «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе «Әйдә, халыкка хезмәткә!» дип исемләнгән фильмнар циклын әзерләгән.**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән төшерелгән әлеге фильмнарда, исемнәннән аңлашылганча, халкыбыз тарихында эз калдырган, татарга хезмәт иткән шәхесләр турында сөйләнә. Аяз Гыйләҗев, Хәсән Туфан, Туфан Миңнуллин, Иван Яковлев, Сергей Чавайн, Иван Харитонов – гомумән алганда, тамашачыларга 10 шәхес турында 10 фильм тәкъдим ителәчәк. ДТРКның милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Миңназыйм Сәфәров сүзләренә караганда, әлеге проект бу исемнәрне яңа яктан ачу, ә кайберләре турында киңрәк даирәгә сөйләү максатыннан башкарыла.

– Бездә мондый исемле проект бар иде инде. Аның асылы татарга бүген хезмәт итүче шәхесләр белән аңгәмә кору булса, фильмнар циклында без кайчандыр милләт өчен зур эшләр башкарган, бүген күпмедер дәрәҗәдә онытылып баручылар турында сөйлибез, – дип аңлатты ул безгә.

Кыска гына, 15–20 минутлык, әмма эчтәлекле фильмнары белән халыкка мөрәҗәгать итәргә теләп алар.

– Һәр кеше Җир йөзенә үз миссиясе белән туа. Кемдер ул миссиясен зуррак аренага чыгып үти. Ләкин анысы ул кадәр мөһим түгел. Әлеге фильмнар аша кешеләрне кулларыннан килгәнчә эшкә – халыкка хезмәткә өндәргә телибез. Билгеле, халык – бик зур төшенчә ул. Җәмгыять, диик. Гаиләңә, туган авылыңа, туган төбәгеңә хезмәт ит! Безнең геройлар да юл башында, зур эшләр башкарыйм әле, димәгәннәр. Алар – гап-гади авыллларда туып-үскән, гамәлләре белән зур кеше булган шәхесләр, – ди Миңназыйм абый.

«Әйдә, халыкка хезмәткә!» проекты авторларының берсе Мөршидә Җиһаншина, фильмнар әдәбият дәресләрендә визуаль ярдәмче ролен дә үти, ди.

– Мәктәп укучылары өчен бик файдалы проект. Моны безгә укытучылар шалтыратып та әйтте. Гомумән, проект үз караучысын тапты, бик ошаталар, социаль челтәрләргә урнаштыргач та үнай фикерләр кабул итәбез, – дип өстәде ул.

Аның сүзләренчә, фильмнарны кызыклы итәр өчен, архив материаллары, документлар белән эшләргә, визуаль якны баетырга кирәк. «Яшьләр сурәт алышынып торганны ярата. Хәер, үзебез дә шуңа ияләндек», – ди Мөршидә Җиһаншина.

Проектның тагын бер үзенчәлеге – татар халкына хезмәт иткән башка милләт вәкилләрен дә барлау.

– Әйтик, Иван Харитоновны алыйк. Бездә бит матур гамәлләре белән халык хәтерендә калган шәхесләргә «әби», «бабай» дип әйтәләр. Менә ул да телгә Харитон бабай булып кергән. Узган гасырның иң күренекле наширләренең берсе ул. Гомере буе түбәтәй киеп йөргән, безнең кебек яшәү рәвеше алып барган, балаларын да шулай тәрбияләгән. Аның турында фильм әзерләргә керешкәндә, безнең нибары бер фотосурәт бар иде. Җирләнгән урыны, туганнары – берсе дә билгеле түгел. Каберен өч көн буе эзләдек. Һәм эзләгән чакта уйладым: менә кеше яшәгән, гомерен халкына багышлаган, ә без шул кешенең эзен югалттыкмы? Шулай да, таптым мин ул каберлекне. Җимерелгән, ташланган. Андый кешеләрне шушы рәвешле онытырга ярамый... – дип сөйләде Миңназыйм Сәфәров.

10 фильм белән чикләнергә җыенмый алар. Матди ярдәм булмаса да, үз көчебез белән төшерер идек, ди Миңназыйм абый.

– Гомерем буе басма матбугатта эшләгән кеше буларак, бу проектны әзерләгәндә, мин үземә Америка ачам, рухланам. Бер кеше турында эзләнгәндә, икенчесен «казып» чыгарасың. Кызганыч ки, ул исемнәр халык хәтереннән җуелган, игътибар үзәгеннән төшеп калган. Ә халыкка хезмәт иткән кешеләр – зыялылар бер даирәдә «кайнаган», бер төрле фикер йөрткән, охшаш яшәү рәвеше алып барган. Киләчәктә исемлекне арттырырга ният бар.

Әлеге проект фильмнары «Россия-1» һәм «Россия-24» каналларында күрсәтелә, шулай ук аларны телеканалның «YouTube»тагы сәхифәсендә карарга мөмкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

**Кире кагу**

Извещение опубликованное в газете «Ватаным Татарстан» за номером 66 (28839) от 14 мая 2022 г на листе №4 о повторном собрании участников общей долевой собственности на земельной участок из земель сельскохозяйственного назначения, расположенный по адресу: Актанышский район, на землях СПК «Яхшый» на 27 июня 2022 года 12.00 часов, считать недействительным.

# ҮЧӘЛЛЕНЕҢ ҮҖӘТ КЫЗЫ

Безнекеләр

**Илсөяр апаның тыныч кына ял иткәнен түгел, бер урында утырып эшләгәнен дә күргәнем булмады. Аңа гел нидер эзләргә, кем беләндер очрашырга, аралашырга, кемгәдер булышырга кирәк иде.**

Шуңа карамастан, номер саен бик саллы язмалары да гел чыгып торды. Кайчан язган, ничек өлгергән ул? Элек тә шулай булды, бүген 75 яше тулган көннәрдә дә. Хәзер инде Казан университетының журналистлар әзерләүче бүлеге укытучылары үтенече буенча, язмаларын туплап, китап чыгару эше белән йөри. Студентларга, чыннан да, бик кирәкле әсбап булыр иде ул. Нәкъ менә Илсөяр апа белән бер чорда эшләвемне мин үзем дә олы бәхет дип саныйм.

Кайчагында уйланып утырам да, Илсөяр апага Эшсөяр дигән исем тагын да килешлерәк булыр кебек тоела. Дөрес, ул исем ир-атларга күбрәк бара кебек. Әмма Илсөяр апаның гомер агышында, үзе теләп, юка гына җилкәсенә әйгән эшләрен күз алдыннан үткәрсәң, көчле затлар бер якта торсын. Шунысы да бар: ул башкаларның киңәшләрен, тәкъдимнәрен бер читкә куеп, тормыш юлын, үҗәтләнә-үҗәтләнә, үзе теләгәнчә үтә.

**Хыял**

Мәктәп елларында ук Азнакай районының Үчәлле авылыннан башкалага юл тоткан кыз ул вакытта Казанда икәү генә калган татар мәктәбенең берсенә укырга керә. Кызның авыл кысасына гына сыймаган лидерлык сыйфатлары шунда ук тышка бәреп чыга. Комсомол булмаган килеш аны комсорг итеп сайлап куялар. Дәреслек ачылгач, Идел буе райкомында «утлы таба»га бастыралар, билгеле. Мәктәпне тәмамлагач, Илсөяр, барысын да гаҗәпләндереп, университетның татар филологиясе факультетына юл тота. Югыйсә барлык фәннәрне үз иткән кызга остазлары математиканы сайларга тәкъдим итә. Җитмәсә, ул елларда татар теленең абруе да әллә ни булмый бит. Уку йортын тәмамлагач, Казанда калырга мөмкинлек чыкса да, университетның актив студенты, 113 нче группаның горурлыгы, үзен сынап карау нияте белән, ерак бер авылга укытучы булып китә. Әмма журналист булу теләге аны бер минутка да ташламый. Ни дисәң дә, балачактан килгән хыял бит.

Ул елларда татар матбугаты да санаулы гына, җитмәсә, журналист һөнәре ир-атларныкы булып саналган чак. Зур өметләр белән башкалага әйләнеп кайткан кыз «Социалистик Татарстан» газетасына корректор булып урнаша ала. Ә язасы килә. Илсөяр аптырап калмый, бәләкәй балам бар, дип тә тормый, яз вакытларында мөхәррирдән тема ала да районнарга чыгып китә. Үҗәтлек үзенекен эшли. Аны башта хатлар бүлегенә, аннары фән һәм уку йортлары бүлегенә корреспондент итеп күчерәләр. Тәҗрибәсе арткан саен, Илсөяр апабыз редакция буйлап алга таба «атлый»: пропаганда бүлеге, партия, икътисад, сәнәгать..

**Нефть**

Менә шул икътисад бүлеге аны нефть дөньясына алып керә дә инде. Илсөяр апаның «кара алтын» белән үз алыш-биреше бар. Балачактан өнәп бетерми ул аны. Эш болай була. Бабасы Минһаҗ остаһың йорты Үчәлле авылының кырыенда ук урнашкан. Бу җирләр инде атаклы Ромашкино нефть ятмасына тоташа дип уйланыла. Нефть эзләүче бораулаучылардан бер гаилә бабай йортында өйдәш булып керә. Икегә бүленгән өйнең бер өлешендәге сәке көндезләрен кухня ролен үти. Рәсем ясарга яраткан дүрт яшьлек кыз бала шунда пычак эзләп менә дә, тәшәр юлына ят апа китереп куйган самавырны күрмичә, күлмәк итәге белән аның борынын эләктерә... Шуннан бирле ул озак вакытлар нефтьчеләрне дә, табибларны да өнәп бетерми. Ә менә еллар үткәч...

Бервакыт аны редакциядән Октябрь революциясе ордены белән бүләкләнгән нефтьче янына Ромашкиноның гөмбәзе булган Лениногорскига җибәрәләр. Шушы командировка аның тормышын бөтенләйгә үзгәртә. Ул Татарстан җирләрен Европа илләре кыяфәтенә китерүгә төп өлеш керткән нефть һәм ул эшкә чын күңелдән бирелгән нефтьчеләр дөньясын ача. Узган гасырның болгавыр туксанынчы еллары уртасында «Татнефть»не Татарстанныкы итеп саклап калу өчен, журналистлар да күп көч сала. Хезмәттәшебез Илсөяр апа да, нефть компаниясенә дефолт игълан иттермәү, саеккан ятмалардан алынган сыеклыкка салымны киметтерү өчен, республика һәм федераль журналистлар белән бер сафка басып, каләме белән көрәшкә ташлана. «Без матбугат сүзенә ышану һәм хөрмәт булган чорда эшләдек», – дип әйтергә ярата ул хәзер шул шанлы үзгәртеп кору елларын искә алганда.

**«Рухият»**

Нефтьчеләрнең журналистка булган ышанычы аркасында республикада беренче хәйрия фонды – быел 25 еллыгын билгеләп үткән «Рухият» фондын оештыру һәм аңа башлап җитәкчелек итү Илсөяр Хәйруллинага тапшырыла да инде. Журналистика белән параллель барган бу яңа эштә аның оештыру сәләте, күпкырлы таланты тагын да ачыла төшә. Фондның башкарма директоры булып эшләгән җиде ел эчендә Илсөяр апа катнашы белән 70тән артык китап, альбом дөнья күргән. Алар рәссам Шамил Насыйбов, тарихчы Рамил Миннуллин белән «Шәхесләребез», «Шигърият» сериясеннән ачып җибәрелә. «Көмеш чишмәләр җыры», «Акбүз атым – ак канатым», «Татнефть. История компании», «Ромашкино», «Рәссам Әхсән Фәтхетдинов» альбомнары нәшрият эшчәнлегендә яңа күренеш була. Илсөяр апа хәзер дә, үзләренең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән бергәләп, җиде томлы «Татар тарихы»ның ике томын әзерләү һәм аны спонсорлар акчасына дөньяга чыгара алулары өчен чын күңелдән горурлык кичерә.

«Рухият» дөньяга китергән һәм башкалар эләктереп алган тагын бер башлангыч – ул балаларның иҗат фестивале. Композитор Мәсгудә Шәмсетдинованың хыялыйлыгы белән «Сандугач сайрар илем» исеме бирелгән әлеге фестиваль нефть төбәгенең яшь талантларына Казанга һәм Мәскәүгә тәүге юлларны ачты. Хәзерге көндә фестивальнең дәвам итүе, «Рухият» нәшриятында «Саҗидә Сөләйманова», «Рәис Нәгыймов», «Гамил Авзал» кебек әдәбият-сәнгать әһелләренең альбомнары, Ризаэддин Фәхретдин хезмәтләре һәм башлап язучыларның китаплары чыгып тору – Илсөяр Мәсгут кызы башлаган эшнең кирәкле, шуңа күрә дәвамлы булуы турында сөйли.

**Гаилә**

Белеп торам: бер кеше шуның кадәр эш башкара аламы, дип уйлап куячаксыз. Ә мин, була – артта тераге, иҗат кешесенең күңелен аңлаучы кешесе булса, дип җавап бирәчәкмен.

– Командировкага төрле илләргә, төрле җирләргә барырга туры килде. Франция, Америка, Гарәп Әмирлекләреме ул, әллә инде ерак Себердәге татар авылымы – Нурисламның һичкайчан шелтәләгәнен ишетмәдем. Ул минем өчен зур таяныч булды, – ди Илсөяр апа үзе дә.

Илсөяр Мәсгут кызы Хәйруллина – Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе иясе, «Бәллүр каләм» бәйгесенең беренче лауреаты.

Нурислам абыйның үҗәтлектә бер дә Илсөяр апаның үзеннән ким дип әйтеп булмый анысы. Бер күрүдә үзенә гашыйк иткән кызны берничә елдан соң эзләп таба бит ул. Армиядән кайткач, сыйныфташ кызы белән күрешергә дип, КДУның тулай торагына килә егет. Шунда күзе төшкән Илсөяре ул кичне каядыр юкка чыга. Язмыш аларны кабат очраштыргач, егет инде аны кулдан ычкындырмый. Танышуларына бар ай дигәндә, өйләнешеп тә куялар. Ике кызлары – Сөмбел белән Айгөл үсеп, гаилә кора. Балалар, туганнар – барысы бергә Илсөяр белән Нурислам корган нигезгә җыелырга ярата, чөнки бу йорттан җылылык бөркелеп тора. Илсөяр апаның пешергән ризыклары да телне йотарлык. Бакчасы да – матурлык дөньясы.

Илсөяр апаның тагын бер гаиләсе бар: бу – «Ватаным Татарстан» коллективы. Киткәненә дә күп түгел әле. Кайчан гына, редакция үтенече буенча Дәүләт Советындагы сессияләргә барып, комитет утырышларында катнашып, шундагы хәлләрне җәһәт кенә укучыларыбызга җиткерә иде. Хәзерге көндә дә ул, «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналларының әдәби мөхәррире булып, яшь журналистларга остазлык дәресләре бирә. Әмма кайда гына булса да, без шуны беләбез: Илсөяр апа ул – безнеке, «Ватаным Татарстан»ныкы. Яраткан остазыбызны матур юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

# МАТУРЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

## «КИТАП» РАДИОСЫ КАБАТ СӘФӘРГӘ КУЗГАЛА

**Узган елның көзендә «Китап» радиосы Татарстан һәм Башкортстан районнарында әдәбимузыкаль кичә, дәресләргә, ачык һавадагы концертлар оештырды. Өч көнлек автосәяхәттән кайткач, беренчесе һәм соңгысы түгел, дип вәгъдә дә бирделәр.**

«Татар-информ»

Һәм менә кабат районнар буйлап сәфәр кылырга әзерләнә алар. Беренче әдәби-музыкаль тукталышны инде якшәмбе – 26 июньдә ясачаклар. «Мин матурлык эзләп йөрим...» дип аталган концертлар җәмгысы 14 районда узачак. «Китап»ның башкарма продюсеры Лилия Кадыйрова һәм яшь шагыйрә Сәйлән сезне шигырьләр укып куандырса, баянчы Ильяс Шәрипов, моңлы тавышлы җырчылар Зәринә Хәсәншина, Айрат Ганиев күңелгә якын җырлар башкарып сөендерәчәк.

– Исемнәннән ук аңлашыла: Татарстан районнарында яшәүче кешеләргә матур сүз аша матурлык турында искә төшерәсебез килә. Соңгы 30 ел эчендә эстрадабыз берникадәр үзгәрде. Бүген, бер-ике мисалны искәпкә алмаганда, аның асылы бик, сикерү, шоу ясау, юмор сөйләүгә кайтып кала. Бер яктан караганда, начар түгелдер инде бу. Татар кешесенә тарча контент куллану күнекмәләрен югалтмаска ярдәм итә чөнки. Шул ук вакытта без матур сүз җанрыннан көннән-көн читләшәбез. Рәшит Сабиров, Айрат Арсланов алып барган концертларны хәтерләүчеләр бардыр. Алардан аермалы буларак, бүгенге концертлар күпкә гадирәк, күңел ачу форматына корылган. Безнең максат – бушлай урам концертлары аша дөньяда әле нәфис сүз, шигърият барлыгын, татар миллятенең асылын матур сүз тәшкил итүен искә төшерү, – дип аңлатты «Китап» радиосы баш мөхәррире Алмаз Миргаязов.

Ачык һавадагы концертлар 26 июньнән 11 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Беренчеләре Кукмара белән Арчада узса, Әгерҗе, Менделеевск, Баулы, Урыссу, Лениногорск, Әлмәт, Аксубай, Базарлы Матак, Нурлат, Чирмешән, Буа һәм Чүпрәлене дә урап кайтырга ниятлиләр. Радионың атрибутикасы сурәтләнгән яшел автобус күргәнсез, аптырамагыз. Димәк, сезгә җыр-моң һәм шигърият алып киләләр. Соңыннан башкалада да концертлар булачак. Аларны Казанның Горки-Әмәт, Урицкий, Черек күл паркларында һәм үзәктәге бер сәүдә йорты түбәсендә корылган махсус сәхнәдә уздырырга җыеналар.

– Концертларда вакыт белән сыналган, халыкның күңеленә сеңгән җырлар яңгыраячак. Безнең радионың шигаре дә – «һәрбер өйгә таныш көйләр», милли моңнар һәм Китап». Бездәге җырларның 70–80 проценты тыңлаучыларыбызга кечкенәдән үк таныш. Сыйфат ягын исәпкә алып, концертларда алар заманча башкарылышта яңгыраячак. Элеккеге башкарылышны кабатлап булмый, җырларны бозасыз, диючеләр булыр. Мин дә моның белән күпмедер дәрәҗәдә килешәм. Ләкин алай да тыңламасак, 5–10 елдан алар, гомумән, онытылачак. Һәм без бернинди традицияне, миллилеге булмаган буынга «җәүһәр»ләр белән бергә-бер утырып калачакбыз, – ди Алмаз Миргаязов.

«Безгә концерт белән кайчан киләсез?» Мондый сорауны еш ишетергә туры килә икән аларга.

– Без сезне яратабыз, килегез инде, диләр. Гомумән алганда, «Китап» радиосының мобиль кушымтасын инде 20 меңнән артык кеше куллана. Иң күп тыңлаучылар, билгеле – Татарстан районнарында яшәүчеләр. Шулай ук Уфада бик күп тыңлыйлар. Чит илләрдән Төркия, Испания, Чехия, Канада һәм АКШта да бар «Китап» сөючеләр, – дип сөйләде радионың баш мөхәррире.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары –
ХӘСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 289

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сәйт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булараклык тәкъдим итәлә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+